## АЧЫК МӘЙДАН

**Рөстәм Миңнеханов энергетика һәм энергия саклаучы технологияләр буенча халыкара форумда катнашты**

> 2

## КЕРИМ ӘЛЕ...

**Урманнарны чүп-чардан арындыру эшләренә керештеләр**

> 2

## УКУЧЫ СҮЗЕ

**«ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары**

> 3

## БЕР КАТ АЛ

**Билеттан баш тарткан очракта нинди кагыйдәләрне үтәргә кирәк?**

> 5


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 56 (28829) | Чәршәмбе | 20 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

# АҢЛАМАСАГЫЗ, СОРАГЫЗ!

**15 яшькә кадәрге һәр бишенче укучы үзенең нәрсә укыганын аңламый. Россия Мәгариф академиясе президенты Ольга Васильева «Заманча дөньяда укучы: уңыш формуласы» I халыкара чарада әнә шулай дип белдергән. Аңламагач, белем каян килсен?**

Ольга Васильева китергән бу саннар – укучыларның функциональ грамоталылыгын ачыклау буенча ил һәм халыкара тикшеренүләр нәтиҗәсе. Белгеч әйтүенчә, укуга кагылышлы проблемалар гадәттә башлангыч сыйныфтан урта мәктәпкә күчкәннән соң башлана. Монда «5ле»гә укучылар саны да башлангыч мәктәпкә караганда шактый азрак. Балаларда укуга карата кызыксыну кимү программаның катлауланувына да, балаларның теләгенә, укытучыларның укыту алымнарына һәм башка факторларга да бәйле булырга мөмкин. Россия галимнәре хәзерге вакытта әлеге мәсьәләнең сәбәпләрен өйрәнә.

Функциональ грамоталылык – киң төшенчә. Ул уку, математика, финанс белемнәрен, иҗади фикер йөртә белү сәләтен үз эченә ала. Белем сыйфаты турында сөйләшкәндә, фикерләр икегә бүленә. Укытучылар, «икеле капчыклары»н көчләп укытып булмый, дисә, укучылар, киресенчә, мөгаллимнәр дәресне аңлата белми яки кабатлап сораганны яратмый диләр. Балаларның мәктәпкә мәҗбүри йөрүчеләре дә, шул ук вакытта үз белемнәре белән хәтта акча эшләүчеләре дә бар. Әнә Казан мәктәпләренең берсендә белем алучы Мәрьям Мортазина белем ташын бик яхшы кимергән. Хәзер үзе математикадан башлангыч һәм 5–6 нчы сыйныф укучыларын өйрәтә.

– Укытучы булу җиңел түгел. 1–2 нче сыйныф укучыларына кайбер җөмләләрне хәтта дүрт-биш тапкыр кабатлыйм. Болай эшләгәндә, аңлыйлар. Зуррак укучылар белән андый проблема юк. Иң мөһиме – мин аларга яхшы итеп аңлатырга тиеш. Әгәр аңламасалар, алдагы теманы ничек үтәсең ди? Үзем дә дәрестә төпченеп сорыйм. Башка сыйныфташлар да шулай. Аптыратмагыз, дигән укытучы юк. Башка мәктәпләрдә ничектер – белмим. Укытучыдан да күп нәрсә тора, – ди 11 нче сыйныф укучысы Мәрьям.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Мәктәпләрдә укытучылар да мондый проблемалар барлыгын яшерми. Яшел Үзән районы Күгеш мәктәбенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы Энҗе Исмәгыйлева белдергәнчә, укучы текстны аңлап укымый. Эчтәлек буенча төзелгән сорауларга төгәл җавап бирә алмый. «Нинди генә фәнне үзләштерсә дә, баланың аңлап укуы кирәк. Аңламаса, ул кирәкле мәгълүматны таба алмаячак, гомумән, укуга карата кызыксынуы кимеячәк. Укытучы гаеплеме? Четерекле сорау. Моны уку системасындагы җитешсезлек дияр идем. Ата-ана, бала, мәктәп... һәрвакыт тыгыз бәйләнештә бит, – ди ул. – Баланың сабый чактан ук кулында телефон хәзер, ул шулай күреп кенә мәгълүмат алырга гадәтләнә. Фикерләү сәләте бөтенләй үсми бит. Әгәр дә гаиләдә бу хәл гадәти күренешкә әйләнсә, бакчада да моңа азрак игътибар ителсә, мәктәпкә килгәч, баланың мәгълүматны укып үзләштерүе түбән була дип саныйм. Иҗади фикер йөртүгә бәйле кызыклы биремнәр күбрәк булса, балада укуга кызыксыну уятырга мөмкин».

Зәй районының татар теле һәм әдәбияты укытучысы Зөлфия Нәбиуллинага мондый проблемалар белән очрашырга туры килә.

– Балалар укыйлар, тик анда сүз нәрсә турында барганын белмиләр. Күбрәк укытучы кушканга укыйлар. Китап укыйм дип атлыгып торучылар сирәк. Аларга телефон да җитә, кирәкле мәгълүматны интернеттан табалар. Балаларны гына гаепләп тә булмый. Өлкәннәргә дә әдәби әсәрләр кирәкми. Без кечкенә чакта әнидән качып укый идек. Заманасы шул булган. Әлбәттә, укытучының да өлеше бар. Әсәрне укыганда, кызыксындырып куймасаң, китапка исләре китмәячәк, – ди Зөлфия Нәбиуллина.

Математика укытучысы Мөнирә Садыйкова исә, бөтенләй аңламыйлар, дигән фикер белән килешми. «Бар баланы да бер калыпка салырга ярамый. Ничәдер проценты аңламаска мөмкин. Бу укучының белеменә, сүз байлыгына да бәйле. Игътибар белән уку да җитмәскә мөмкин. Шуңа күрә текстны җентекләп укып чыгарга кирәк. Яшермим, үземнең дә архитектурага кагылышлы темаларны кат-кат укыганым бар. Миңа 9 нчы сыйныф укучылары имтихан биремнәрен күтәреп килә. Апа, берни аңламадык, диләр. Шул теманы чәйнәп каптырырга туры килә. Балаларны гаепләмим. Бик акыллы, фәнни телдә сөйләүчеләренә шаккатам», – ди Мөнирә Садыйкова.

Үзе дә 2 нче сыйныфта белем алучы оныгы белән хикәяләр, шигырьләр укый икән. «Күп сүзләргә аңлатма кирәк, эчтәлекне аңлау өчен рәсемнәр ярдәм итә. Рәсемнәр бирелмәсә, үзем ясыйм. Хәзер балаларның теле соң ачыла. Тел кимчелекләре, авазларны дөрес әйтмәү дә текстны аңлауга комачаулый, гадәттә андый балалар дөрес интонация белән өлкәннәр укуын аңлыйлар», – ди мөгаллимә.

Идел буе мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм кабат әзерләү үзәге директоры урынбасары Ләйсән Мингалиева да, мондый проблема бар, ул PISA халыкара тикшеренүләр нәтиҗәсендә ачыкланды, диде. Республикада ачылган Укытучыларның белем осталыгын күтәрү үзәгендә мөгаллимнәрне укучыларның грамоталылыгын үстерүгә дә өйрәтәләр икән.

Ишеттегезме?

# Май аеннан – яңа түләү

**Озакламый балалар өчен яңа түләүләр бирелә башлый. Россия Президенты Владимир Путин 8–16 яшьлек балаларга айлык яңа пособие турында указга кул куйды.**

Түләү 1 апрельдән билгеләнә. Ә инде 1 майдан шушы айлык пособиегә гаризалар кабул итү башлана. Акча берьюлы ике ай – апрель һәм май өчен биреләчәк. Шунысы да бар: апрельдә балага 8 яшь тулган булырга тиеш.

Моңа кадәр мондый пособие баласын ялгыз тәрбияләүче ана яки аталарга гына тәгаенләнде. Менә хәзер, майдан башлап, аны авыр тормышлы тулы гаиләләр дә алачак. Әлеге ярдәмне ил буенча барлыгы 5 миллион балага билгеләү күздә тотыла.

Түләүнең төп шарты – гаиләнең җан башына туры килә торган кереме төбәктә билгеләнгән яшәү минимумыннан кимрәк булуы. Моннан тыш бала даими рәвештә Россиядә яшәргә тиеш. Гаилә керемена социаль түләү булмаган барлык акча – хезмәт хакы, премия, пенсия стипендия һ.б. керә. Әйтик, җирле бюджетлардан матди ярдәм, социаль контракт буенча, торакка яки транспортка түләүләр кебек социаль ярдәм керем исәбенә кертелми. Аннан килеп, пособие алу өчен гаилә соңгы 12 айда азмы-күпме керемгә ия булганлыгын да расларга тиеш. Мәсәлән, эшсезлек, 3 яшькә кадәрге баланы карау сәбәпле, керемсез утыручыларга моны дәлилләү кирәк. Юкса пособие бирелмәячәк. Шулай ук милек буенча чикләүләр дә бар. Мәсәлән, зур фатир яки коттеджда яшәп, рәсми керемнәре булмаган гаиләләр дә юк түгел. Мондыйларга да пособие түләнми.

Яңа түләү төбәктә бала өчен билгеләнгән яшәү минимумының 50, 75 яки 100 процентын тәшкил итәргә мөмкин. Иң кечкенә күләме – уртача 6 мең сум (50%), арттырылган күләме – 9 мең (75%), ә иң зур күләме – 12 мең сум (100%) тәшкил итә. Минималь пособие гаиләнең җан башына керемен яшәү минимумына җиткермәсә, арттырылган күләмдәгесе бирелә. Болай да гаиләнең уртача кереме аз булып калса – максималь түләү күздә тотыла.

Яңа пособиене алу өчен, «Мир» картасы яки картасыз счет ачарга кирәк. Түләү 12 айга билгеләнә. Шуннан соң аны озайту мәсьәләсе карала.

Сүзгә-сүз

**Александр ГРУНИЧЕВ, Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе:**

Тарифларга килгәндә, аларның зурлыгы буенча Идел буе федераль округында беренче урында торабыз, димәс идем. Шул ук вакытта республика аларның минималь дәрәҗәсе буенча да беренче урында түгел. Без «Идел буе федераль округындагы иң югары тарифлар» дигән тәнкыйтьне ишетмәслек «алтын урталык»та торабыз, дип саныйм.

**(«Татар-информ» агентлыгына биргән интервьюдан)**

## РОССИЯДӘ – ҺӨНӘР САЙЛАУ

**Maximum Education белем бирү программасы оештырган сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Россиядә быел 11 нче сыйныфны тәмамлаучы чыгарылыш укучыларының 42 проценты киләчәктә нинди һөнәр сайлаячагын белми. Төгәл карар кылучыларның хыяллары түбәндәгечә.**



| | |
|---|---|
| Иҗат өлкәсенә караган һөнәр | 21% |
| IT юнәлеш | 17% |
| Икътисад өлкәсенә караган һөнәр | 13% |
| Психолог | 9% |
| Галим | 7% |
| Педагогика, юриспруденция, сәламәтлек саклау тармагы белгече | 6% |

## Кибет киштәләре тулы

Татарстанда инде ике атна дәвамында тоз, ярма, шикәр комыише озак сакланышлы азык-төлеккә ихтыяҗ кимү күзәтелә. 7–13 апрель чорында аларны куллану, уртача күрсәткеч белән чагыштырганда, якынча 13 процентка кимегән. Салым федераль хезмәтенең контроль-касса техникасы мәгълүматлары шуны күрсәтә.

Шул ук вакытта Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы вәкилләре муниципалитетлар белән берлектә көн саен кибет киштәләренең тулылыгын барлауны дәвам иттерә. Икътисад министрының беренче урынбасары Рөстәм Сибгатуллин әйтүенчә, сәүдә нокталарында һәм складларда халык өчен җитәрлек күләмдә товар запасы булдырылган. Кибетләрдә беренче чиратта кирәкле барлык товарлар бар. Шәһәрдә яшәүчеләрне сыйфатлы продукция белән тәэмин итү өчен, 19 марттан бирле авыл хуҗалыгы ярминкәләре үткәрелеп килә. Анда чагыштырмача арзан бәядән азык-төлек сатып алырга мөмкин.

## *Уку гимннан башлана*

Мәктәпләрдә яңа уку елыннан һәр дүшәмбе саен дәүләт гимны башкарылачак һәм әләм күтәреләчәк. Бу хакта мәгърифәт министры Сергей Кравцов мәктәп укучыларының «Сила – в правде!» I Гомумроссия тарихи форумында белдерде.

Хәтерләсәгез, узган елның октябрь аенда Президент Владимир Путин Хөкүмәткә Россия гербын, флагы һәм гимнын мәктәпләрдә куллану мәсьәләсен карап тикшерүне йөкләгән иде. Премьер-министр Михаил Мишустин 13 апрельдә барлык уку йортларын рәсми дәүләт символикасы белән тәэмин итүне күздә тоткан карарга кул куйды.

## Бушлай җир бирелә

Татарстанда күпбалалы гаиләләрнең 64,2 проценты бушлай җир кишәрлекләре белән тәэмин ителгән. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы хәбәренә караганда, Казанда бу күрсәткеч 40,7 процентка тигез.

Хәзерге вакытта республикада барлыгы 73630 гаиләнең җир кишәрлеген бушлай алу хокукы бар. Шуның 67488е буенча исемлеккә кертү турында карар кабул ителгән. Әлегә мондый гаиләләргә барлыгы 42523 кишәрлек бирелгән.

## *Казан – беренче*

Россия шәһәрләренең җәмәгать транспорты рейтингында Казан беренче урынга чыккан. Югары икътисад мәктәбе галимнәре тикшеренүендә ул 212 балл туплаган. Фәнни хезмәттә, Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан тыш, 50 шәһәр мәгълүматлары исәпкә алынган. Рейтинг транспортның уртача сыешлыгы, автобус һәм трамвай өчен билгеләнгән юлларның озынлыгы, «пик» сәгатьләрендә җәмәгать транспортыннан файдаланучы пассажирларның максималь саны, электр транспортының өлеше кебек күрсәткечләр буенча төзелгән. Екатеринбург икенче урынга чыккан. Новокузнецк – өченче. Шулай ук Новосибирск һәм Ижевск шәһәрләре дә «иңиң»нәр бишлегенә кергән.

Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Казанда транспорт өчен бүлеп бирелгән юллар башка шәһәрләрдәгедән озынрак – 85 чакрымнан артык. Башкалабыз бу күрсәткеч буенча якындагы көндәше Красноярскидан 50 чакрымга диярлек «узган». Казан шулай ук яңартылган трамвай юлларының гомуми озынлыгы буенча да лидерлыкка чыккан.

## Бурычлының мөлкәтенә – арест

Татарстан приставлары бер атна эчендә бурычлыларның 115 миллион сумлык мөлкәтенә арест салган. Шул исәптән 153 автомобиль (55 миллион сумлык) хуҗаларыннан вакытлыча алынган. Суд приставлары хезмәте идарәсендә искәртеп үтелгәнчә, пристав бурычлы кешенең мөлкәтенә арест салуга хокуклы. Тормыш тәҗрибәсеннән күренгәнчә, бу чара әҗәтне түләтүнең иң нәтиҗәле ысулы булып тора. Мөлкәтенә «богау» салынган кешегә аннан файдалану тыела. Кирәк булганда, приставлар аны бөтенләй тартып алырга да мөмкин.

Суд приставлары бурычларны вакытында түләргә киңәш итә. Ә инде бурычлымы-юкмы икәнлегеңне «Банк данных исполнительных производств» сервисы аша тикшереп карарга мөмкин. Анда әҗәткә кагылышлы барлык мәгълүматлар күрсәтелгән.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

**Дөньяда**

## ХУШ КИЛӘСЕҢ, СТАГФЛЯЦИЯ?

Җир шарында моңарчы күрелмәгән бөек үзгәрешләр тезмәсе дәвам итә. Дәүләтләр яңа коалицияләр төзергә азапланалар, яңа икътисади һәм хәрби аркадашлар эзләнә, доллардан качу тенденциясе көчәя, углеводород базарларын үзгәртеп кору башланды һәм кызулана... Кыскасы, без турбулентлык дип атарга гадәтләнгән уңга-сулга, аска-өскә чайкалу дәвамлы булырга охшаган. Куркыныч вазгыять бу, чөнки дәүләт түнтәрелешләре, төбәк конфликтлары, астыртын рәвештә аркага пычак кадаулар вәгъдә итә. Гегемонлыгын югалтып баручы АКШ, дилбегәне кулда тотарга азапланып, көтелмәгән адымнар ясарга ихтимал. Европага океан артыннан атом-төш коралын китерүгә старт бирелде инде. F-35 бомбага тотучы очкычларының күпләп юк итү коралын йөртергә сәләтле модификациясе Англиягә төшеп утырырга җыена. Бу стелс очкычларны радарлар күрми диярлек, шуның белән алар куркыныч. Әлегә америкалылар дипломатик басым ясау юлы белән дәүләтләрне үз якларына аударырга омтылалар. Һиндстанга, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә, Непалга, Германиягә һәм Польшага Вашингтон сенаторлар десанты җибәрергә җыена. Америка Финанс министрлыгы: «АКШ барлык илләрнең дә Россиягә каршы санкцияләргә кушылуын тели», – дип белдерде инде. Йогынтысы какшаса да, Американың зур хәрби куәте һәм икътисади басым ясау мөмкинлекләре кала әле. Буйсынмаган Якын Көнчыгыш һәм Африка илләрендә ачлык оештыру һәм аларны фетнә зонасына куып кертү – алар өчен потенциаль яктан мөмкин эш. Икътисады әнә-менә түнәм дип торган Кытайга аяк чалу да Вашингтонга артык кыен түгел. Кытайларның 3 триллион доллардан артык резервлары АКШның әҗәт кәгазьләренә тыгылган һәм океан арты державасын какшату, аның белән кискен конфликтка керү Азия гиганты өчен хәвефле. Бу дүшәмбедә Пекин хакимиятләре быелның беренче кварталында икътисади үсешнең 4,8 процент булуын игълан иттеләр. Кытай өчен бу – кечкенә сан, әмма чит ил белгечләре аның да бармактан суырылган булуын әйтәләр.

Financial Times – халыкара эшлекле даирәләр газетасы, быел дөнья икътисадын стагфляция көтә, дип язды, ягъни икътисади түбәнәю бәяләр күтәрелеше белән җитәкләшеп барачак. Капитализмның классик кризисы, җитештерү кимегәндә, бәяләрнең түбәнәюе белән характерлы. Товарны сату өчен базарларның бәяне төшерүе – аңлашыла торган нәрсә. Шунсыз җитештерүнең яңа югарылыгына чыгу мөмкин түгел. Әмма бүген бу формула кулланыла алмый инде. Күбрәк җитештереп, күбрәк сатыйм дип бәя төшерү булмаячак. Күз алдыгызга китерегез: икътисадның кирегә китүе сәбәпле, миллионнар эшсез калып, урамга куылачак, шул ук вакытта аларның элеккеге запасларга өметләнеп яшәү мөмкинлеге бетәчәк. Булган бөтен финанс резервларын инфляция ашаячак чөнки. Моңарчы күпме теләсә, шуның кадәр доллар басып, матди проблемаларын хәл итәргә күнеккән АКШның да андый куәте бетәчәк. Акча басып, пособиеләрне мул өләшәсең икән, сине дә бәяләрнең йөгәнсез күтәрелеше көтә дигән сүз бу. Моңа юл куймас өчен океан артында барысын да эшләргә тырышачаклар. Шуңа күрә алдагы айларда, бигрәк тә көзге якларда барыбызга да бөек түнтәрелешләрдән торган «кино» карау ихтималы үсә.

**Россиядә**

## ДОЛЛАР САТЫП АЛУ

Россия дә шул стагфляция кысасында яши. Тимер кыршау белән кысылганлыктан, безнең икътисадта ул көчлерәк чагыла, бары тик шул гына. Быел икътисади түбәнәю 10 процент һәм аннан да зуррак булыр дип көтелә. Бу – рәсми игълан ителгән сан. 1992 елгы мәтәлчек белән генә чагыштырып була моны. Инфляциянең зур адымнарыннан без элегрәк валюта сатып алып котылырга тырыша идек. Озак сабыр итсәң, валюта паникасы булып, кайчан булса да бер әҗерен күрми калмыйсың. Махсус хәрби операция безнең андый шаяртуларга чик куйды: банклар доллар һәм евро сатуны туктаттылар. Әмма гаҗәп хәл: сум ныгып, безне яңадан февраль ае долларына кайтара язды. Бер генә китеклек бар: каты сумга йомшарган долларны сатып алып булмады. Бу кимчелекне Үзәк банк төзәтә башлады. 18 апрельдән валютаны сатуга чыгарырга рөхсәт бирелде. Бик чикләнгән күләмдә генә сәүдә башланырга тиеш иде. Банклар 9 апрельдән соң үз кассаларына кергән валютаны сата алалар. Сәүдәнең төп кагыйдәсе шул. Арчадагы банк кассасына валюта каян килә ала? Сумның ныгуына ышанып, кемнәрдер кире паникага бирелсә һәм итек кунычындагы валюта запасларын банкка китереп тапшырса гына. Газета хәбәрчесе, бу юлларны язу өчен, сишәмбе көнне «Ак Барс банк»ка шалтыратып, валюта сатып алырга теләге булуын җиткерде һәм курсны белеште. Җавапның нинди булачагы мәгълүм иде инде: сатмыйлар, Үзәк банк курсыннан күпкә түбәнрәк бәягә алалар гына.

Ил күләмендә вазгыять шундый. «Российская газета» журналистлары, банкларның валюта сатучы тәрәзәләре янында бик озак йөреп, идән асты сәүдәсенә охшаган ысул белән 20 мең сумга 200 доллар ала алганнар. Банкирлар: «Без сату хокукы алдык, сатарга мәҗбүр ителмәдек», – дип әйтәләр ди. Валюта алыштыру пунктларында доллар сатып алырга теләүчеләр дә күренми икән, димәк, ажиотаж юк. Кешеләр, күрәсең, я валюта сәүдәсенә ышанмыйлар, я шулкадәр фәкыйрьләр: долларга алыштырырлык сумнары юк.

Бик сирәк банклар гына 95 сум тирәсеннән доллар сата икән сатуын. Алар да бер кулга мең доллардан артык бирми. Үзенең премиум клиентларына гына валюта сатучы банклар бар. Премиум клиент статусына ия булу өчен, я банкта эшләргә кирәк, яисә аның хисабында зур суммада даими акча тотарга. Кыскасы, бик бай булсаң, валюта сатып ала аласың. Казан банкларының берсендә дә валюта сату турында мәгълүмат табып булмады. Долларны 78–81 сумнан сата аласың, бернинди бәядән дә сатып алу ихтималлыгы юк. Моның объектив сәбәпләре бар һәм күп, әлбәттә. Әмма сиңа валюта кирәк икән, объектив сәбәпләрдән ни файда? Гамбург хисабы буенча долларның чын курсын белү мөмкин түгел шулай итеп. Бик тырышсаң, 95–100 сумга табып була, дип әйтәләр әйтүен. Төрек банкларында сум курсы ныгыган. Элек 200 сумга бер доллар бирүче банклар бар иде, хәзер 145кә дә саталар, дигән хәбәр алдым.

# САКЛАУ ДА МӨҺИМ

**Кичәге көн башкалада тулысынча энергия, энергия саклау мәсьәләләренә багышланган иде. Иң элек Казанда энергетика һәм энергия саклаучы технологияләр буенча Татарстан халыкара форумы ачылды. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән Россия Президенты ярдәмчесе Игорь Левитин катнаштылар. «Казан Экспо»да узган әлеге чарада Россиянең 34 төбәгеннән 63 оешма катнаша. Шунда ук Россия Дәүләт Советының энергетика буенча эш төркеме утырышы да узды.**

Рөстәм Миңнеханов әлеге форумны бу тармак үсешенә этәргеч бирерлек карарлар кабул итүче белгечләр, сәнәгатьчеләргә фикер алышу өчен ачык мәйданчык дип бәяләде. «Энергия нәтиҗәлелеге һәм әйләнә-тирәне саклау – икътисадның көндәшлеккә сәләтен арттырган, халыкка яшәү өчен уңайлы шартлар тудырырга этәргеч биргән бурычларыбыз. Форумда катнашучыларның уртак эше барлык дәрәҗәдәге элемтәләрне үстерергә, фәнни-техник мөмкинлекләрне ныгытырга ярдәм итәр дип ышанам. Без тәҗрибә уртаклашырга, аралашырга әзер», – диде Президент.

tatarstan.ru

Форум ачылышында катнашкан Россия Президенты ярдәмчесе Игорь Левитин бу форумның энергия саклау тармагында, бигрәк тә йортлар төзегәндә яңа технологияләр кулланырга мөмкинлек бирүен искәртте. «Россия җитештерүчеләренә хәзерге шартларда үз технологияләренә күчү өчен менә дигән мөмкинлек тә бу», – диде ул.

Энергия саклаучы технологияләргә багышланган махсус күргәзмәдә «Татэнерго», «Татэнергосбыт», «Татнефть» кебек эре оешма вәкилләре җитештерү күрсәткечләре, яңа проектлар белән таныштырды. Оешмаларның җылылык челтәрләрендәге югалтуларны киметүен, үзебездә җитештерелгән җиһаз һәм технологияләр куллануга йөз тотуын да искәртте алар.

«Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турында» Татарстанның Министрлар Кабинеты утырышында да шул хакта сөйләштеләр.

Республиканың сәүдә һәм сәнәгать министры Альберт Кәримов сүзләренә караганда, бүген Татарстанда электр энергиясенә кытлык күзәтелә. «Узган ел төбәктә сәгатенә 32 млрд кВт электр энергиясе тотылган. Бу күрсәткеч 10 процентка арткан. Ул республикада сәнәгать җитештерүе артуга бәйле. Узган ел аның күләме 4 триллион сумнан арткан. Шул ук вакытта электр энергиясе җитештерү дә 13 процентка артып, сәгатенә 27 млрд кВт тәшкил итте. Әмма дефицит барыбер саклана. 2025 елга Татарстан аннан тулысынча котылыр дип көтелә. Бу күмәртәләп сату базарына чыкмыйча эшләячәк объектлар кертү хисабына башкарылачак», – дип сөйләде министр.

Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында килеп туган вазгыятьтә җиһаз һәм технологияләргә импорт алмаштыруны иң мөһим мәсьәлә дип атады. «Җирле технологияләрне кертү – милли куркынычсызлык мәсьәләсе ул», – диде Президент. Энергия нәтиҗәлелеге түбән булган район башлыкларын да тәнкыйть утына тотты ул.

– Муниципалитетларда кулланылган энергия күләмен киметү өчен резервлар бар. Актаныш районында җылылык буенча күрсәткечләр республика күләмендәге уртача саннан 1,5 тапкыр күбрәк. Балык Бистәсендә исә бу күрсәткеч 27 процентка артык. Әлеге районнарда исәпләү җиһазлары белән тәэмин ителешнең түбән булуын күрәбез. Ышанычлы һәм сыйфатлы исәп алып бармау нәтиҗәседер бу. Район башлыкларына үзләрендәге энергия куллану дәрәҗәсен анализлап, муниципаль электр саклау программасын эшләргә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент энергия нәтиҗәлелеге иң аксаган тармак дип торак-коммуналь хуҗалыкны атады. «Су белән тәэмин итү челтәрендә 30 процент энергия югалган очраклар бар. Муниципалитетларда тикшерү уздырып, җиһазларның торышын, никадәр тузганлыгын ачыкларга кирәк. Цифрлы технологияләр кертү дә мөһим», – дип белдерде ул. Бу җаваплы эшне республиканың Цифрлаштыру, Архитектура һәм төзелеш министрлыкларына йөкләде. «Энергия нәтиҗәлелеге – бөтен дәрәҗәдәге оешмалар, хөкүмәт, һәркем катнашырга тиешле комплекслы программа ул. Системага салынган эшебез билгеләнгән бурычларны хәл итәргә булышыр дип өметләнәм», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Россия Дәүләт Советы эш төркеменең энергия нәтиҗәсен арттыруга багышланган утырышында Рөстәм Миңнеханов энергияне сак һәм нәтиҗәле тоту проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә дәүләт ярдәмен күздә тотарга тәкъдим итте.

– Яңа дәүләт программасында чагылдырырга кирәкле чаралар турында берничә сүз. Предприятиеләрнең энергияне сак тоту проектларына аяк салучы сәбәпләрнең берсе – кредитлар буенча ставкаларның артуы. Мондый проектлар буенча эшләүче предприятиеләргә дәүләт ярдәмен күздә тотарга тәкъдим итәм, – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанда Энергияне сак тоту технологияләре үзәге эшләп килүен билгеләп үтте. Ул мондый үзәкләргә, предприятиеләргә энергияне сак тоту мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтү өчен, тиешле вәкаләтләр бирүне һәм федераль үзәктән финанслашуны күздә тотарга тәкъдим итте.

Президент сүзләренә караганда, 2011–2014 елларда энергияне сак тоту буенча төбәк программаларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан да акча бирелеп килгән. Һава торышына бәйле рәвештә җылылык узелларын һәм исәпләгечләр урнаштыру, урамнарны яктырту һәм башка проектларга кагылган бу. Аның әйтүенчә, мондый чыгымнарны үзәктән финанслашуны яңартып җибәрү кирәк.

Шул ук вакытта Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, техниканы табигый газга күчерүне һәм КриоАЗСлар төзүне субсидияләүне федераль программаларга кертү максатка ярашлы булачак.

## *Гозерләр игътибар үзәгенә алынды*

Каравай бистәсендә амбулатория эшләячәк, балалар китапханәсенең Халыклар дуслыгы йорты белән хезмәттәшлеге җайга салыначак. «Бердәм Россия» партиясе рәисе Дмитрий Медведевның төбәк иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә шул хакта мәгълүм булды. Биредә партиянең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин халык гозерләрен тыңлады.

Казанның Авиатөзелеш районы Каравай бистәсендә яшәүче хезмәт ветераны Динә Зенцова парламент җитәкчесенә җирле пенсионерларның үзләре өчен бик тә уңайлы амбулаториядән мәхрүм калулары турында сөйләп үтте. Динә ханым әйтүенчә, 2020 елга кадәр алар 12 нче шәһәр хастаханәсе амбулаториясенә йөргән. Әмма пандемия башлангач, хезмәткәрләр җитмәү сәбәпле, аны япканнар һәм пенсионерларны сырхауханәгә җибәргәннәр. Тик анда кайчан барсаң да, су буе чират. Шуңа күрә өлкән яшьтәгеләргә амбулатория эшен торгызу бик мөһим.

Баксаң, Сәламәтлек саклау министрлыгы бу мәсьәләнең чишелешен тапкан да икән инде. Динә Мансуровнаны тыңлагач, Фәрит Мөхәммәтшин анда яшәүчеләрнең гозере буенча, министрлыкның Каравай бистәсендәге амбулаториядә медицина хезмәткәрләренең дежур торуын оештыру карарына килүен әйтте. «Коронавирус таралу куркынычы, әлбәттә, бар әле, әмма аның кимүе күзәтелә, – дип билгеләп үтте парламент башлыгы. – Шуңа күрә министрлык белән бергә амбулатория эшен ничек тә тулырак торгызырга тырышачакбыз».

Республика балалар китапханәсе директоры Ирина Мөхәммәтгәрәева Фәрит Мөхәммәтшинга Халыклар дуслыгы йорты белән хезмәттәшлекне оештыруга булышу үтенечен җиткерде. Ул, республиканың балалар һәм яшьләр китапханәләре эшенә кагылып, милли-мәдәни автономияләр вәкилләре катнашындагы уртак чаралар, китап бәйрәмнәренең милләтара дуслык-татулыкны тагын да ныгытачагын әйтте.

Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Халыклар ассамблеясы советы рәисе буларак, Ирина ханымга тәкъдиме өчен рәхмәт белдерде. Халыклар дуслыгы йорты җитәкчелегенә Республика балалар китапханәсе белән хезмәттәшлек итү турында килешү әзерләргә кушты.

Башка мәсьәләләр белән мөрәҗәгать итүчеләр дә булды. Аерым алганда, Донбасстан килгән балаларны бездәге тормышка җайлаштыру, WorldSkills чемпионатының республика этабында җиңүчеләр өчен Дәүләт Советына экскурсияләр оештыру мәсьәләләре күтәрелде.

Партиянең Татарстан төбәк бүлеге Секретаре барлык мөрәҗәгатьләрне контрольгә алды.

## Парламентлар арасындагы дуслык

Фәрит Мөхәммәтшин Кыргызстан парламентының Бюджет, икътисад һәм салым сәясәте комитеты рәисе Данияр Толонов белән очрашты. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Россия – Кыргызстан хезмәттәшлеге кысасында парламентара элемтәләрне үстерүгә ышанычын белдерде. Парламентчылар шулай ук хезмәттәшлекне киңәйтү һәм аның яңа төрләрен эзләп табу мәсьәләләрен карады.

Кыргызстан Республикасы делегациясе Казанга «Энергетика. Ресурсларны сак тоту-2022» Халыкара махсус күргәзмәсендә катнашу өчен килде. Чара бу көннәрдә «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәгендә уза. Форумда энергиянең нәтиҗәсен үстерү буенча карарлар кабул ителә. Быел анда Россиянең 34 төбәгеннән 63 компания катнаша.

Кыргызстан делегациясе әгъзалары ике көнлек визит барышында Казан һәм Яшел Үзән районындагы кайбер предприятиеләрдә булырга, шулай ук республика энергетика тармагының эше белән танышырга ниятли.

# УРМАНЧЫ ӨМЕТЕ – ХАЛЫКТА

**Яшәеш**

**Быел урман утырту эшләре ун көнгә соңга кала. Урманчылар агач утыртуга 25 апрельдә керешәчәкләр. Урманнарны торгызу һәм яңарту эшләре «Экология» илкүләм проектының «Татарстанда урманнарны саклау» төбәк проекты ярдәме белән башкарыла. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган очрашуда Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтте.**

tatarstan.ru

– 2024 елда урманнарда күпме агач киселсә, шуның кадәр үсенте утыртачакбыз. Әлегә утырткан агачлар белән киселгән һәм зыян күргәннәренең мәйданнары нисбәте 83,4 процентны тәшкил итә. Тагын ике елдан без аны 100 процентка җиткермәкче булабыз, – ди министр. – Быел урманчылар ярдәме белән 3619 гектар җиргә урман утыртачакбыз. Шулай ук авыл хуҗалыгы җирләрендә дә агач утырту булачак. Безгә бу эштә эре сәнәгать оешмалары да булыша. Алар ярдәме белән быел барлыгы 8264 гектарда агач үсәчәк.

Равил Кузюров сүзләренчә, республикада утырту чималына кытлык юк. Кәлшәләр үзебездә дә җитәрлек. Республиканың төрле районнарында урнашкан 55 питомникта һәм Урман селекция-орлыкчылык үзәгендә 34,1 миллион данә кәлшә җитештерелгән. Шуларның 25,5 миллион данәсе – ылыслы, 7,9 миллион данәсе – яфраклы агачлар, 700 мең данәсе – куак.

– Урманнарны чүп-чардан арындыру эшләренә керештек. «Татарстанның чиста урманнары» дигән республика акциясе башланды. Әлеге чара 2010 елдан бирле үткәрелә. Ул ике этапта узачак. Беренчесе – 18 апрельдән 18 июньгә, икенчесе 12 сентябрьдән 12 ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Акция кысасында урманны көнкүреш калдыкларыннан, корыган агачлардан арындырачакбыз. Шулай ук урман буйларында ял итү урыннарын, мәгълүмат такталарын яңартачакбыз, – ди Равил Кузюров.

Сүз уңаеннан, узган ел әлеге акция вакытында Татарстан урманнарыннан 2 мең кубометр чүп чыгарылган. 3 мең кубометр корыган агач җыелган. 24 чишмә төзекләндерелгән. 230 элмә такта яңартылган, 175 ял итә торган урын чистартылган. Чистарту акциясендә 20 мең кеше катнашкан.

Ни өчен урманнарны чистартуга зур игътибар бирелә соң? Озак уйлыйсы юк: урман эчендәге чүп-чар, корыган агач янгынга сәбәп булып тора. Министр да шулай ди. Аны бигрәк коры үләнгә ут кабу, чүп-чар яндырып, урманга зыян салу очраклары борчый.

– 25 апрельдән 15 майга кадәр республикада янгынга каршы көрәш режимы кертелә. Аеруча бу чорда урманда янгын чыгу куркынычы зур. Шунлыктан, әлеге чорда урманда учак ягу, шашлык пешерү бөтенләй тыела, – ди министр.

Урманчыларның бар өмете – халыкта. Янгыннарга юл куймас өчен, алар урман янәшәсендә яшәүчеләр белән даими очрашып, сөйләшүләр уздыра, янгынга каршы тору өчен барысын да эшли. Министр әйтүенчә, урман янгынын сүндерү станцияләре дә бар, техника да җитәрлек. Ут чыгу очракларын булдырмау өчен, быел күктән дә күзәтәчәкләр. Инде алдан язганыбызча, коры үләнгә ут капкан очракта, министрлыкка хәбәр килеп тора. Алар үз чиратында әлеге очракны урманчылыкка хәбәр итә. Шулай итеп, урманга ут капмый кала.

– Урманнарга басулардан ут күчмәсен өчен, махсус полосалар да ясалды. Кисәтү язулары да эленде. Кешеләргә безнең аңлату барып җитсен иде. Ут бит тиктомалдан гына чыкмый. Саклык кирәк. Тагын бер проблема: соңгы елларда кешеләр урманнарга якын җирдә йорт сала башлады. Бу бигрәк куркыныч тудыра. Әгәр кеше мунчасын ягып, торбадан очкын агачларга оча икән, янгын буласын көт тә тор. Көннәр дә кызу булса, уттан котылам, димә. Шуңа күрә урманга якын яшәүчеләргә кат-кат бу хакта аңлатабыз. Урманнарны бергәләп кенә саклап була, – ди ул.

Очрашуда министрдан бәйрәмнәрдә шашлык пешерергә ярау-ярамавын да сорадылар. Ул исә: «Әгәр янгын куркынычы булмаган җирдә яшисез икән, өсте каплаулы мангалда пешерәсез яки җиргә чокыр казып, учак ягасыз икән, ярый», – дип җавап бирде. Әмма кат-кат кисәтте: ут яккан кеше җаваплылыкны онытмаска тиеш. Урман һәм бакча янәшәсендәге йортларда яшәүчеләргә сабыр итеп торырга туры киләчәк. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозучы кешеләргә – 3 мең, вазыйфаи затларга – 20 мең, юридик затларга 200 мең сум штраф каралган. Ә инде янгынга каршы көрәш режимы кертелгәч, бу саннар тагын да арта. Ул вакытта гади халык – 4–5 мең, вазыйфаи затлар – 20 меңнән 40 меңгә, юридик затлар 300 меңнән 500 мең сумга кадәр акча түләргә тиеш була.

Равил Кузюров әйтүенчә, агач утырту 30 апрельдә башлана. Бу «Хәтер бакчасы» акциясе Казанда дүрт урында узачак. Әлеге акция яу кырында ятып калган 378 мең якташыбызга багышлана. Барлыгы 1 миллион төп агач утыртырга җыеналар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«Каен суын бу атнадан соң җыюдан мәгънә юк. Ул витаминнарын югалта. Каен суын агачка зыян китермичә генә алырга ярый. Моның өчен кечкенә генә тишек тишеп (2 мм), шуннан су җыясыз. Күпме бирәсен агач үзе хәл итә. Артык суны чыгармый ул».

УКУЧЫ СҮЗЕ

# БҮЛӘК – ХӨРМӘТ УЛ

Яз җиттеме, әдәбият, сәнгать өлкәсендә ыгы-зыгы башлана. Әйтерсең лә бер атаның малын үксез балалары бүлешә. Ул «мал»ның берсе артыннан икенчесен теләнеп йөрүчеләр дә булды, һәм бу күренеш әле дә бетеп җитмәде.

Нәрсә соң ул бүләк? Берәүләр аны, иҗатчының яшенә карамыйча, иң яхшы әсәрләре өчен бирелә торган «мал» дип саный. Икенче берәүләр, яшьләр түзәр, өлкәннәргә бирергә кирәк, ди. Астыртыннары, әсәрләрдә түрәләрне мактау хәерле, дип йөрүчеләре дә бар.

Син якыннан белгән теләсә кемнең кулына тоттырып буламы ул бүләкне? Минем туксан яшен тутырган әни капка төбенә чыгып утырса, аңа конфет тоттырып китәләр иде. Ул кешеләр әнине күптәннән белә, аның җитмеш яшендә дә баш түбәсендә капчыкка тутырылган печән күтәреп кайтканын хәтерлиләр иде. Кыскасы, алар әнине тырыш, хезмәт сөючән булганы өчен хөрмәт иттеләр. Бу әдәбият, сәнгать өлкәсендә дә шулай булырга тиеш. Бүләкне аеруча хөрмәтле кешегә тапшыру хәерле.

Бүген, тормышның төрле баскычларыннан менеп, аска тәгәрәп, кабат күтәрелгән, шигърият диңгезендә дә бата-чума йөзеп, калкып чыккан, нурлы йөзе, хөр тавышы белән балкып торган кем бар? Күпләр минем белән килешер, ул – Флера Гыйззәтуллина. Мин аны күптәннән, бик күптәннән хөрмәт итәм. Мин хөрмәт иткән кешеләр арасында Рәниф Шәрипов, Нәҗибә Сафина, Илсөяр Иксанова да бар. Ләкин аларны әлегә Флера Гыйззәтуллина белән янәшә куеп булмый. Бездә талантлы яшьләр дә күп, ләкин аларның үзләренә тиешле, «яшьрәк» бүләкләр бар. Күргәнемчә, коры калмыйлар шикелле.

Ә фән өлкәсенә килгәндә, аның аерым Дәүләт бүләге бар бит. Тарихчылар – шулай ук хөрмәтле кешеләр, ләкин алар – фән кешеләре.

Бүтән милләт кешесенә Тукай бүләге биреп буламы дип кызыксынучылар бар. Ник булмасын?! Әгәр ул кеше татар әдәбиятына, аның сәнгатенә өлеш кертә һәм халык тарафыннан хөрмәт ителә икән, саранланмаска кирәк. Рус милләтеннән булган Александр Ключарев татар җырларын аз иҗат иттеме? Аның борынгы җырларга да игътибары зур булды. Ключаревны Татарстанда да, Мәскәүдә дә хөрмәт иттеләр. Татарстан Дәүләт бүләген Лев Гумилевка да биреп була иде. Милләтебезнең үткәне һәм бүгенге язмышы турында аз кайгыртмады бит ул!

Заманында хөрмәтле шагыйрьләр арасында буразнада тәгәрәгән Кадыйр Сибгатуллин, кече яшьтән таш арасында чуалган чандыр Рәшит Әхмәтҗанов бар иде. Җирнең ыңгырашуын сиземләгән Кадыйр, ташның куәтенә сокланган Рәшит кемнәргәдер ошамады. Хәер, алар теләнмәде, Кремль диварлары арасында буталып йөрмәде дә.

Бүләкләрнең берсе артыннан икенчесен өмет итүчеләр арасында рус язучылары бар иде. Мәсәлән, Михаил Бубеннов, ансат кына Сталин премиясен кулга төшергәч, Ленин премиясенә дә омтылып карады. Әмма аның таланты халык хөрмәтенә лаек дип табылмады.

Бүләккә лаек дип, иҗатчыларны төркемнәре белән тезеп кую – сәер күренеш, билгеле. Лаеклы кешеләрне алдан ачыкламыйча һәм шау-шу куптармый гына бүләкләп булмас микән? Кешене көтелмәгән бүләк куандыра бит.

Әнис ЗАРИПОВ.
Казан

# «Пушкин картасы» яктылыкка, нурга илтә...

«Пушкин картасы»ндагы акчаны китапханәгә бару өчен дә кулланырга була хәзер. Түбән Кама китапханәләр берләшмәсендә әлеге юнәлештә эш уңышлы гына тормышка ашырыла.

Берләшмә директоры Гөлназ Арсланова башлангычы белән 2021 елның ноябрь аеннан ук китапханәләрдә экскурсияләр уздырыла. 2022 елда «Пушкин картасы» буенча чараларны берничә мәйданчыкта – Габдулла Тукай исемендәге үзәктә, «Апуш» балалар китапханәсе, Кол Гали исемендәге милли китапханә, «Заман» уку һәм аралашу үзәгендә үткәрә башладык. Мәктәп укучылары да, студентлар да әлеге чараларга бик теләп йөри. «Китап дөньясы белән якыннан танышабыз, үзебез өчен күп яңалык ачабыз. Китапханәчеләр очрашуларны кызыклы һәм файдалы итеп оештыра», – ди егет-кызлар.

Түбән Кама китапханәләре вакыт белән бергә атлый. Укучылар белән эшләүнең, аларны китап укырга җәлеп итүнең яңа алымнары, юллары эзләнелә. Осталык дәресләре, язучылар, кызыклы шәхесләр белән очрашулар оештырыла. Психологлар, медицина белгечләре катнашында чараларга да яратып йөри укучыларыбыз. Яңа проект яшь буында мәдәният, сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләргә булышып кына калмыйча, әлеге тармакны үстерүгә дә өлеш кертер дип өметләнәбез.

Роза АНИКИНА.
Түбән Кама

# БАКЧАБЫЗНЫҢ ЙӨЗЕК КАШЫ

Әлмәт шәһәрендәге «Шаян нәниләр» бакчасында тәрбияче булып эшләүче Вера Мөхәммәтдинова турында бу сүзләр. Ул – Лениногорск районының Федотовка авылы кызы. Кечкенәдән үк тырыш, ярдәмчел, чая, матурлыкны күрә белә торган булып үсә. Әнисенең – назлы кызы, сеңлесенең – яраткан апасы, апасының иркә сеңлесе була.

Мәктәптә укыганда укытучы булачакмын дип хыяллана. Минзәлә педагогия училищесын тәмамлап, 1981 елда туган авылындагы башлангыч мәктәпкә укытучы булып кайта. Яшь белгечкә балалар белән эшләү бик ошый. Эшендә зур нәтиҗәләргә дә ирешә.

Гаиләләре белән Әлмәт шәһәренә күченеп киткәч, бертөрлелекне өнәп бетермәгән Вера Ивановна, үзен яңа һөнәрдә сынап карарга теләп, тәрбияче булып урнаша. «Бер төркем сабыйлар, самими күзләр... Көн саен яуган мең сорау... Шулар мине мәңгелеккә балалар дөньясында калдырды», – дип хискә бирелә ул.

Шул елларда булачак тормыш иптәше Рамил белән таныша. Гөрләтеп туй үткәрәләр. Ике уллары туа. Тик язмыш аңа зур сынау җибәрә: гомер иткән сөекле ире мәңгелеккә күзләрен йома. Югалтуны бик авыр кичерә ул. Ике улы – Ринат белән Руслан аның өчен юаныч була. Алар әниләрен бар яклап та куәтләп тора. Әниләре барлык авырлыкларны, сынауларны үтеп, яраткан эшенә бирелә.

Ул безгә – яшь тәрбиячеләргә энциклопедия кебек. Нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәң дә, җавабын тиз һәм гади итеп аңлата белә. Аңардагы бетмәс идеяләр, заманча тәкъдимнәр белем һәм тәрбия бирүне тагын да кызыклы итә. Коллективыбызда шундый тәҗрибәле, милли җанлы хезмәттәшебез булуы белән горурланабыз.

Күптән түгел Вера Ивановнага 60 яшь тулды. Без аны күркәм юбилее белән тәбрик итәбез. Аның бик бәхетле гомер кичерүен телибез.

Регина НУРГАЛИЕВА.
Әлмәт шәһәре

## ТНВ КАНАЛЫНДА – ЯҢА СЕРИАЛ

ТНВ каналы үзенең тамашачылары өчен «Алмаш» исемле яңа сериал төшерә. Хәзерге вакытта рольләргә актерлар сайлау бара. Съемкалар җәй көне башланачак.

Яңа фильм өчен актерларны студиядә сайлап алалар. Алар белән сериалның баш режиссёры Алмаз Әкбәров эшли. Камера алдында чыгыш ясау театр сәхнәсеннән шактый аерыла.

«Алмаш» фильмындагы төп рольләрне башкаручылар инде билгеләнгән. Алар – Татарстанның халык артистлары Фирая Әкбәрова, Әсхәт Хисмәт, Искәндәр Хәйруллин.

Яңа сериалның асылында авыл һәм шәһәр тормышы, замана проблемалары торачак. Әлбәттә, мәхәббәт тә була.

«Алмаш» сериалын республиканың берничә районында төшерәчәкләр. Хәзер техник әзерлек алып барыла. Яңа сериалны «ТНВ-Татарстан» һәм «ТНВ-Планета» каналларында күзен карый алачаксыз.

12+

# Сере бик гади икән

Сүзем – укытучы һөнәрен сайлап, 47 ел гомерен шуңа багышлаган Рәшит Фәтхинур улы Галимуллин турында. Ул Пермь өлкәсенең Кизел шәһәрендә туган. Әти-әнисе Шәмәкнеке булсалар да, әтисе шахтада эшләү сәбәпле, шунда төпләнгәннәр. Ләкин туган якны сагыну хисе үзенекен итә.

Рәшит Галимуллин хезмәт юлын 1975 елда Шүләңгер мәктәбендә башлый. 1982 елда педагогия институтының физмат бүлеген тәмамлаган егетне Җәнлек совхозы мәктәбенә математика фәнен укытырга җибәрәләр. Аннан Сәкинәс, Тәкәнеш, Тауиле мәктәпләрендә эшли. 2012 елдан бирле – туган авылында мәктәп директоры. Россия Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы, «Мәгарифтәге хезмәтләр өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә. Яшь вакытларын исенә төшергәндә: «Шүләңгергә Шәмәктән җәяү йөреп эшләдек бит без», – дип искә ала ул. Үзе эшләгән вакытларда, грант отып, Тауиле мәктәбен интернет челтәренә тоташтыра.

Аларның нәсел җепләрен барлый башласаң, укытучылар династиясе дип горурланып сөйләргә була. Чөнки туганнары Нурия Габдрахманова белән Хәмит Әлмиев – Татарстанның атказанган укытучылары, Шәһит Гайфуллин – 47 ел стажы булган өлкән укытучы, Гөлсинә Гайфуллина, Рәхилә Галимуллина, Римма Әгъләмҗанова, Лариса Гайфуллина... Барысының да хезмәт стажларын санасаң, 300 елдан артып китә. Рәшит Галимуллин укыткан укучылар арасында да укытучы һөнәрен сайлап, мәктәп директоры дәрәҗәсенә җиткәннәр күп. Лариса Гайфуллина – Түбән Тәкәнеш, Илдар Муллахмәтов Тауиле мәктәбен җитәкли. Бу исемлектә тагын күпләр бар әле.

Рәшит абый, лаеклы ялда булуына карамастан, авылыбыз мәктәбе коллективын җитәкләвен дәвам иттерә. Барысы белән уртак тел табып эшли ул. Безнең кебек мәдәният өлкәсендә хезмәт куючылар өчен авылда мәктәп булу – зур куаныч. Ни генә кушсалар да, киңәшләшеп эшлибез. Рәшит абыйдан: «Гомер буе коллектив белән ничек шулай дус эшләргә була?» – дип сорыйбыз. Сере бик гади икән. «Эштән курыкмаска, балалар, коллектив, ата-аналар белән уртак тел табып, бар эшнең дә яхшы ягын, кешеләрнең дә яхшылыкларын гына күреп эшләргә, яшәргә кирәк», – ди ул.

Гөлия МОСТАФИНА

# БАЛА... МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА ҖЫРЛЫЙ

Бер минем өчен генә түгел, күпләр өчен таныш, сәер халәт бу. Башлангыч сыйныф укучылары сәхнәгә чыга да мәхәббәт турында җыр суза. Андый чакта, бала никадәр моңайса да, кайда безнең композиторлар, балалар өчен җыр язучы калмады микәнни, дип читенсенеп, аптырап утырасың.

Шулай сәерсенеп йөргәндә, РФ Президентының мәдәни башлангычлар фонды игълан иткән беренче бәйге грантларын отучылар мәгълүм булды. Грант отучылар арасында үзебезнең татарстанлылар да бар. Бәхет елмайганнардан музыка белгече, композитор Әлфия Һадиева проекты безгә аеруча кызыклы тоелды. Ул эшен «Балалар өчен җырлар җыентыгы» дип тәкъдим иткән. Без аның белән очрашып, әлеге проекты турында сөйләвен сорадык.

– Бу проект китап чыгаруны гына күздә тотмый. Эш интернетта сайт белән бергә барачак. Әлеге сайт педагоглар өчен аралашу мәйданы булыр, балалар бакчаларының музыка җитәкчеләре дә аннан үзләренә кирәкле мәгълүмат алыр дип ышанам. Кыскасы, «Хәерле көн» дигән проект ике юнәлештән гыйбарәт: берсе – китап-җыентык, икенчесе – укытучылар өчен шул исемдәге сайт-платформа.

Китапка фортепианода уйнау өчен балаларга атап язылган ноталы, аккомпанементлы кырык җыр керәчәк. Күп кенә балалар бакчаларында, мәктәпләрдә фортепианода уйныйлар, нотага карап, балалар белән өйрәнәләр.

Китап рәсемле булачак. Тәрбиячеләргә, укытучыларга атап чыгарылгач, рәсем нигә кирәк, нота җитмәгәнмени, дип әйтергә дә мөмкиннәр. Соңгы вакытта шулай чыгаралар да. Билгеле, алай арзангарак төшә. Болай да балалар китабына акча күп бирелми инде. Минем хыялым – һәр җырны рәсем белән бизәп чыгару. Элек нәшер иткәннәр ич. Күптән түгел генә 1962 елда чыгарылган шундый бер җыр китабына тап булдым (совет вакытында балалар җырлары симфоник оркестрлар катнашында да башкарылган). Анда ноталар да, рәсемнәр дә бар. Ул миңа бик ошады. Мондый җырларны бергәләп тыңлаганнан соң, тәэсирләрегезне ничек күзаллыйсыз, шуны рәсем итеп ясагыз, дип балаларга бирем бирергә мөмкин.

Җыеп әйткәндә, без балалар бакчалары һәм башлангыч сыйныф укучылары өчен репертуар тупладык. Китапның тагын бер үзенчәлеге шунда: ул ике телдә булачак, ягъни билингваль. Бу мәсьәлә хәзер бик актуаль.

Китапка керә торган җырларның бер өлеше тамашачыларга таныш. Яңалары да шактый. Шул ук вакытта нотасы белән рәсмиләштереп бирелгәч, аның көен төгәл итеп җырлыйсың. Билгеле, иҗатыма, илле яшемә ясалган бер нәтиҗә дә булачак бу эш.

yold.ru

Китапның эчтәлегенә килгәндә, җыентыкка тупланган җырларның төп өлеше туган якка, әти-әнигә, әби-бабаларыбызга багышланган. Балаларны туган җиргә, ватанга мәхәббәт хисләре, кыскасы, патриотик хисләр белән тәрбияләргә кирәк. Аерым бер өлешен «Җырлы-биюле уеннар» хасил итә. Билгеле, уен җырлары беренче чиратта бәләкәчләргә адресланган. Аларны балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр, башлангыч сыйныф укучылары да башкара ала. Гадәттә, сабыйларны җырларга хәрәкәт аша өйрәтәләр. Алай үтемлерәк була, тизрәк истә кала.

Мин бу китабымны беренче чиратта әти-әниемә багышлыйм. Иҗат кешесе булып үссен дип, алар минем өчен бик күп көч түкте. Сабый чагым балалар бакчасында узды диярлек. Әнием бакчада эшләгәч, мәктәпкә укырга кергәч тә, буш вакыт булган саен шунда барам, алар өйрәнгән шигырь-җырларны мин дә отып калам. Мөгаен, күңелдә туган хис-кичерешләрне җырга салу теләге шунда уянгандыр.

Грантта катнашып җиңеп чыгу – бер хәл. Әле аны гамәлгә ашырасы бар. Чөнки грант – проектның бер өлешен финанслау гына. Калган өлешен финанслау өчен җитди матди ярдәм кирәк. Бик кирәкле эш бу, дип Рөстәм Сәрвәров ашыктырып торганда, шәт, нәтиҗә озак көттермәс, – дип сөйләде безгә Әлфия ханым.

Рәшит МИНҺАҖ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе хакында һәм Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләнгән затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы 1 кисәге һәм 37 статьясы 2 кисәге нигезендә **карар бирәм**:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибен расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» яисә Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турында указ чыккан көннән алып 30 көн дәвамында түбәндәге күләмнәрдә бирелә:

Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләнгән ата-аналарга (уллыкка яки кызлыкка алучыларга) – 100 мең сум. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләнгән ата-аналарның (уллыкка яки кызлыкка алучыларның) берсенә түләнә;

Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән, биш бала тәрбияләп үстергән аналарга – 50 мең сум;

Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән, алты яисә аннан күбрәк бала тәрбияләп үстергән аналарга – бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләме алтынчы балага һәм аннан соң килә торган һәр балага хисаплап, бүләкләү көненә аларның өч яше тулган булу шарты үтәлгәндә, тиешенчә 10 мең сумга арта;

б) бүләкләнгән зат вафат булган очракта, әгәр аңа бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк тапшырылмаган булса, бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мирас буларак тапшырыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау хакында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-875 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 августындагы ПУ-684 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-231 номерлы һәм 2020 елның 11 августындагы ПУ-475 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибенең 1 пунктындагы икенче абзацка, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Әлеге Тәртипнең гамәле Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре – «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.».

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 13 июнендәге ПУ-424 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-231 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе турында нигезләмәнең 6 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«Ата-ана фидакарьлеге» медале;»;

б) сигезенче – унбишенче абзацларны тиешенчә тугызынчы – уналтынчы абзацлар дип санарга.

6. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе турында» 2000 елның 2 ноябрендәге ПУ-828 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 23 июлендәге ПУ-494 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 27 февралендәге ПУ-106 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале тасвирламасын, аңа таныклык формасын (үрнәген) һәм бүләкләү кәгазе формасын раслау турында» 2010 елның 22 июнендәге ПУ-397 номерлы Указының 2 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-876 номерлы Указының 1 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 14 мартындагы ПУ-232 номерлы Указы.

7. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узганнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 15 апрель
№ ПУ-284

Татарстан Республикасы
Президентының 2022 елның
15 апрелендәге ПУ-284
номерлы Указы белән расланды

**Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе**

1. Әлеге Тәртип нигезендә Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турында үтенечнамәләрне (алга таба тиешенчә – үтенечнамә, медаль), шулай ук үтенечнамәгә кушымта итеп бирелүче документлар һәм белешмәләрне карау процедурасы билгеләнә.

2. Үтенечнамәләр оешмалар коллективлары, җәмәгать берләшмәләре, дәүләт органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары тарафыннан кузгатыла.

3. Үтенечнамә кузгатылганда, Татарстан Республикасы Президенты раслаган форма буенча бүләкләү кәгазе тутырыла.

Бүләкләү кәгазен рәсмиләштерүче һәм аңа кул куючы затлар анда күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген тәэмин итә.

4. Әлеге Тәртипкә кушымтада күрсәтелгән документлар теркәп бирелгән үтенечнамә һәм бүләкләү кәгазе (алга таба – бүләкләү документлары) «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү хокукы булган дәүләт органнарына (вазыйфаи затларга) (алга таба – бүләкләүгә тәкъдим итәргә вәкаләтле органнар) җибәрелә.

Бүләкләүгә тәкъдим итәргә вәкаләтле органнарга үтенечнамәне һәм бүләкләү документлары оешмалар коллективлары, җәмәгать оешмалары, дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырыла.

5. Бүләкләүгә тәкъдим итәргә вәкаләтле органнар үтенечнамәне һәм бүләкләү документларын аларны теркәгән көннән соң 30 календарь көн эчендә карый.

6. Медаль белән бүләкләүгә тәкъдим итүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

аларга карата үтенечнамә кузгатылган затларның Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында законнарда Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булырга мөмкин затларга куелган таләпләргә туры килмәве ачыкланганда;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясында каралган нигезләр барлыкка килгәндә;

әлеге үтенечнамә тиешле категория гражданнарны Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә тәкъдим итү хокукы булмаган дәүләт органына бирелгәндә;

үтенечнамә әлеге Тәртиптә каралган документлардан башка бирелгәндә.

7. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итүдән баш тарту турында сәбәпләре күрсәтелгән бәяләмә тутырыла, ул бирелгән үтенечнамә һәм аңа теркәп бирелгән бүләкләү документлары белән бергә үтенечнамәне кузгаткан оешма коллективына, җәмәгать берләшмәсенә, дәүләт органына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органына җибәрелә.

Медаль белән бүләкләүгә тәкъдим итүдән баш тарту сәбәбе бетерелгән очракта, үтенечнамә һәм бүләкләү документлары кабат бирелергә мөмкин.

8. Медаль белән бүләкләүгә тәкъдим итү үтенечнамә һәм бүләкләү документлары белән бергә Татарстан Республикасы Президентына бирелә.

Татарстан Республикасының
«Ата-ана  фидакарьлеге»,
«Ана даны – Материнская слава»
медальләре белән бүләкләү
турындагы үтенечнамәләрне
карау тәртибенә кушымта

**Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләргә теркәп бирелә торган документлар* һәм белешмәләр исемлеге**

1. Ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) паспортының расланган күчермәсе.

2. Балаларның туу таныклыгының расланган күчермәсе.

3. Никахлашу турындагы таныклыкның (булган очракта) расланган күчермәсе.

4. Ата-аналарның (уллыкка яки кызлыкка алучыларның) һәм балаларының фамилиясен, исемен, атасының исемен алыштыру фактын (андый фактлар булган очракта) раслаучы документлар.

5. Хәрби частьлар һәм хәрби комиссариатларның хәрби хезмәттәге балаларга кагылышлы белешмәләре.

6. Балаларның һәлак булуының, хәбәрсез югалуының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^{1}$ статьясының 4 кисәгендә һәм 11 статьяның 4 кисәгендәге 2 пунктта күрсәтелгән шартларын (андый шартлар булганда) раслаучы документлар (шул исәптән хәрби частьлар, хәрби комиссариатлар белешмәләре).

7. Ата яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының), баланың (балаларның) вафат булуы очрагында – вафат булу турында белешмәнең күчермәсе.

8. Гаиләгә һәм ата-анага (уллыкка яки кызлыкка алучыга) (атага яисә анага (уллыкка яки кызлыкка алучыга**) характеристикалар.

9. Балаларның һәм ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) уку, эш урыныннан белешмәләр.

10. Ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри башка түләүләр буенча бурычлары булмау турында белешмә.

11. Белем бирүгә, сәламәтлек саклауга идарә итү органнарының, граждан хәле актларын теркәү органнарының, территориаль социаль яклау органнарының, территориаль эчке эшләр органнарының һәм Татарстан органнарының, территориаль эчке эшләр органнарының һәм Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районында (шәһәр округында) төзелгән балигъ булмаганнар эшләре комиссиясенең ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) балаларын тәрбияләүгә мөнәсәбәте турындагы белешмәләр бирелгән бәяләмәләре.

12. Ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) һәм аларның балаларының социаль активлыгын раслаучы документлар (дипломнар, грамоталар, иҗтимагый чараларда катнашу турында таныклыклар һәм башка документлар), гаилә турында массакүләм мәгълүмат чараларында басмалар (булган очракта).

13. Ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгының бәяләмәсе***.

14. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең бәяләмәләре***.

15. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне алу өчен Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты реквизитлары.

---

Искәрмәләр:

* Әлеге Исемлекнең 5, 8–11, 13, 14 пунктларында санап кителгән документлар бер ел дәвамында гамәлдә дип санала.

** Ата яисә ана (уллыкка яки кызлыкка алучы) вафат булган яисә ана Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән очракта.

*** Бәяләмә Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале яисә Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турында үтенечнамә, бүләкләү кәгазе, әлеге Исемлекнең 1–12 пунктларында күрсәтелгән документлар һәм мәгълүматлар нигезендә алар теркәлгән көннән соң 30 календарь көн дәвамында әзерләнә.

---

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясенең
19 апрель, 2022 ел,
№170/1446 карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Менделеевск районы территориясендә оештырылган сайлау участокларының участок сайлау комиссияләре, Минзәлә районы территориясендә оештырылган № 1974 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе составлары резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Менделеевск районы территориясендә оештырылган сайлау участокларының участок сайлау комиссияләре, Минзәлә районы территориясендә оештырылган № 1974 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе составлары резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр итә. Тәкъдимнәр һәм кирәкле документлар кабул итү Татарстан Республикасы Менделеевск районы территориаль сайлау комиссиясе тарафыннан, Татарстан Республикасы Минзәлә территориаль сайлау комиссиясе тарафыннан 2022 елның 20 апреленнән 6 майга кадәр эш көннәрендә – 08.00–17.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты – 12.00–13.00 сәгатькәчә) хәл ителә.

Түбәндәге адрес буенча:

| Территориаль сайлау комиссиясе (ТИК) атамасы | Территориаль сайлау комиссиясе адресы |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Менделеевск районы ТИК | 423650, Менделеевск ш., Фомин ур., 7 й., тел.: (85549) 2-79-03 |
| Татарстан Республикасы Минзәлә районы ТИК | 423700, Минзәлә ш., Ленин ур., 80 й., Тел.: (85555) 3-10-75 |

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 29 статьясындагы 1 пунктындагы таләпләргә туры килмәүче затлар, тәгаенләп әйткәндә:

– Россия Федерациясе гражданлыгына ия булмаган затлар, шулай ук чит ил гражданлыгына ия булучы яки Россия Федерациясе гражданинының чит дәүләт территориясендә даими яшәүгә хокукын раслаган башка документка ия булучы Россия Федерациясе гражданнары;

– законлы көченә кергән суд карары нигезенә эшкә сәләтсез, эшкә сәләте чикләнгән дип танылган Россия Федерациясе гражданнары;

– 18 яшькә җитмәгән Россия Федерациясе гражданнары;

– дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары, җирле үзидарә органнары депутатлары;

– сайланылулы вазыйфаи затлар, шулай ук җирле хакимиятләр башлыклары;

– судьялар (отставкадагы судьялардан тыш), прокурорлар;

– суд карары нигезендә комиссияләр составыннан чыгарылган затлар, шулай ук комиссияне таркату нәтиҗәсендә хәлиткеч тавыш хокукы белән комиссияләр әгъзалары вәкаләтләрен җуйган затлар (комиссия тарафыннан закон бозулар өчен суд тарафыннан үзләренә карата гаепләрнең юклыгы билгеләнгән затлардан тыш) – тиешле суд карары законлы көченә кергәннән соң биш ел эчендә;

– үзләреннән хөкем җәзасы алынмаган затлар, шулай ук сайлаулар һәм референдумнар турында законны бозган өчен суд тәртибендә административ җәзага тартылган затлар – административ җәза билгеләү турында суд карары законлы көченә кергәннән соң бер ел эчендә, кандидатуралары кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертү өчен кирәкле документлары булмаган кандидатуралар участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертелми.

**Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертү өчен кирәкле документлар исемлеге**

**Сәяси партияләр, аларның төбәк бүлекләре, башка структур подразделениеләре өчен:**

1. Сәяси партиянең яки төбәк бүлегенең, сәяси партиянең башка структур подразделениесенең участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында сәяси партия уставы таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

2. Кандидатуралар турында тәкъдим сәяси партиянең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе тарафыннан кертелеп, сәяси партия уставында мондый тәкъдим кертү мөмкинлеге күздә тотылмаганда – сәяси партиянең төбәк бүлегенә, башка структур подразделениесенә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертүгә вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле сәяси партия органының әлеге вәкаләтләрне бирү турында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

**Башка иҗтимагый берләшмәләр өчен:**

1. Иҗтимагый берләшмәнең гамәлдәге уставының нотариуста расланган яки иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле органы раслаган күчермәсе.

2. Иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары яисә төбәк бүлегенең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының яисә иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә иҗтимагый берләшмә исеменнән мондый карар кабул итүгә хокук бирелгән иҗтимагый берләшмәнең башка структур подразделениесе карары.

3. Кандидатуралар турында тәкъдимне иҗтимагый берләшмәнең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе кертеп, иҗтимагый берләшмә уставында 2 пунктта күрсәтелгән мәсьәлә җайга салынмаганда – иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү буенча вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле иҗтимагый берләшмә органының мондый вәкаләтләрне бирү турында карары һәм әлеге вәкаләтләр бирелгән органның участок сайлау комиссияләре составлары резервына тәкъдимнәр кертү турында карары.

**Участок комиссияләре составлары резервына кандидатуралар кертү хокукының башка субъектлары өчен**

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары, яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыны буенча сайлаучылар җыелышының беркетмәсе. Сайлаучылар җыелышы беркетмәсенең формасы Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, № 152/1137-6 карары (Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 1 ноябрь, 2017 ел, № 108/903-7 карары редакциясендә) белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә № 3 кушымтада китерелгән.

**Моннан тыш кандидатуралар кертү хокукының барлык субъектлары тарафыннан түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш:**

1. Россия Федерациясе гражданинының хәлиткеч тавыш хокукы белән участок сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләнүенә, участок комиссияләре составлары резервына кертүгә язмача ризалыгы (Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, № 152/1137-6 карары (Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 1 ноябрь, 2017 ел, № 108/903-7 карары редакциясендә) белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә № 1 кушымта).

2. Россия Федерациясе гражданины паспорты яки кандидатурасы участок комиссияләре составлары резервына кертү өчен тәкъдим ителгән затның гражданлыгы һәм яшәү урыны турында мәгълүматлардан торган Россия Федерациясе гражданины паспортын алыштыручы документы күчермәсе.

Искәрмә. Документлар үрнәкләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына «Сайлау комиссияләре» бүлегендәге «Участок комиссияләре составлары резервы» «2022 елда участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә кертү» бүлекчәсенә урнаштырылган.

---

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясенең
19 апрель, 2022 ел,
№ 170/1441 карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Тукай районы территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү турында хәбәре**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 22, 26 һәм 29 статьяларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 15 һәм 18 статьяларына таянып, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Тукай районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуына бәйле рәвештә, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Тукай районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләү өчен кандидатура буенча тәкъдимнәр кабул итү турында игълан итә.

Документлар 2022 елның 20 апреленнән 6 майга кадәр, эш көннәрендә 09.00–18.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты: 12.00–13.00), түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420111, Казан ш., Батурин ур., 7 б й., (элемтәгә керү өчен телефон: 8(843) 292-84-33).

Территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга кандидатура буенча тәкъдимнәр керткәндә, «Муниципаль берәмлекләрнең территориаль сайлау комиссияләрен, сайлау комиссияләрен, округ һәм участок сайлау комиссияләрен формалаштыру тәртибе турында методик рекомендацияләр хакында» 17 февраль, 2010 ел, № 192/1337-5 Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карарына таянырга кирәк.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

*Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана*

**БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ**

# КҮРШЕЛӘР

**Туган авылым Югары Стәрлегә кайтсам, Бари бабайларның, башкортлар әйтмешли, ябай гына ихаталары урынына карап, хатирәләремне яңартам. Без бәләкәй чакларда авыл имамы иде ул.**

Тыкрык буенда лай-сәмән кирпече белән салынган кечкенә генә салам түбәле йорт хәзер хәтердә генә яши. Кайткан-киткәннәр имам ихатасы нигезендә дога кылып китә. Әйе, йорт та исән түгел, аның белән хәтердә кайбер мәгълүматлар да юкка чыккан икән. Әйтик, мулла-имамыбызның фамилиясен дә, әтисе-фәләне кем икәнне дә хәтерләмим. Хәер, бер мин генә түгел, ул авылдашлар өчен бик хөрмәтле Бари бабай исеме белән йөртелә иде.

Аң халык безнең авылдан гына түгел, тирә-яклардан, тагын да арырак, Башкортстан җирләреннән, ямьле Ык буйларыннан атлы арбаларда, җиңел машиналарда агыла иде. Чөнки Бари бабайның карчыгы Сакатның даны да еракларга таралган. Карчыкның кулы да, тыны да шифалы дип сөйлиләр иде. Шуңа бер бүлмәле бәләкәй чоланлы өйнең ишекләре һәммә кеше өчен ачык һәм монда китерүче сукмак берчак та өзелми.

Минем инәкәй дә, сыер саугачмы яки сөтен аертып, каймагын кул инде тустаганына тутыруга, сыйлы-җылы чагында, көлчәсен, телем-телем таба күмәчен төйнәп, безне Бари бабайларга кертеп җибәрә иде. Бу бит инде узган гасырның 60 нчы елларына таба, ни дисәң дә кешеләрнең ипекәйләргә тамагы туйган, бөтенәйгән, өй-ихаталарның бик матур төстә үсешкә барган чаклары. Бари бабайның гына ихатасы бер үзгәрешсез. Ләкин йорт-кура һәрчак төзек, чистапөхтә иде. Аларның түрдәге чыгырлы коеларына да күпләр агыла. Мөгаен, суы йомшак, чәйне бик тәмле, хуш исле иткәнгә шулай булгандыр. Юкса авылда башка коелар да җитәрлек.

Бари бабайның авылыбыз имамы булып китүе дә гыйбрәтле. Ул Беренче Бөтендөнья сугышында әсирлеккә эләгә һәм Германиягә бер немец баена хезмәтче итеп җибәрелә. Инвалид әткәй янына кереп утырган чакларында, андагы хәлләрне үтә канәгатьләнү тәсендә, һич тә авырсынмыйча сөйли иде. «Шушында миңа мәдрәсәдә дин дәресләре алырга да мөмкинлекләр тудырыльды, әсирлектән котылганда мин әлифне таяктан аерырлык мәгълүматка ия булып кайткан идем инде», – дип әйтә иде. Әсирлектән котылып, авылга кайткач та, ул бөтен дикъкатен мәчеткә сала һәм беркайчан да бу изге әманәтенә хыянәт итми – гомеренең ахырына тикле авылыбыз имамы вазыйфасын башкара. Әлбәттә, дини тәрәккыятның бу вакытларына нык ихтыярлы, көчле йөрәклеләр генә үз сүзләрендә, үз кыйблаларында нык тора алганнар. Әтәвенә аны колхозга кермәгән өчен дә тәрле яклап кысрыклыйлар. Һәр кешегә карата ихлас ярдәмчеллеге, гадилеге, гадел сүзенә тугры калуы аны бу чорда репрессия машинасына эләгүләрдән дә коткарып калгандыр дип уйлыйм.

Инде ничә дистә еллар үткәндә дә авылыбыз имамы булган күршебез Бари бабайны үтә дә кешелекле өчен һәрчак искә алалар. Бу хәерле гамәлләре аның гел күңел түрендә, үрнәк булып, алдагы буыннарга күчә бара.

Мин хәзерге күршебезнең дә нәкъ Бари бабай кебек ихлас, бик ярдәмчел булуына шатланып яшим. Альберт Хөсәенов – Сәпәй авылының бик абруйлы имамы, соңгы елларда бу үтә җаваплы һәм мактаулы вазыйфаны башкара. Дөресен әйтергә кирәк, аңарчы авылда дини гыйлем тәрбиясе бик йомшарган иде. Альберт хәзрәт дини гыйлемгә өйрәнүгә күп көчен, тырышлыгын биргән. Замандаш күршемнең һич вакыт белән исәпләшмичә, авылыбызда дини тәрбия бирүдәге фидакарьлеге олы мактау-ихтирамга лаек дисәк, бик дөрес булыр. Көнне бише тапкыр азан әйтеп, намазга чакыру кебек иң изге вазыйфалар да тукталган иде чөнки, хәзер исә һәммә дини бәйрәмнәр, яшьләргә, өлкән яшьтәгеләргә мәдрәсәдә дин сабаклары бирү үз вакытында үтә. Гомумән, абыйлы-энеле Илгиз, Роберт, Альберт Хөсәеновлар шәһәр янәшәсендәге Сәпәй авылыбызда дин гыйлеме алып баруны үзләренең изге бурычлары итеп, Аллаһы Тәгаләнең олы рәхмәтенә ирешәләр. Тагын да бәрәкәтле уңышлар, озын-озак сәламәт гомерләр телик игелекле күршеләремә.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы



# «ЯРДӘМЛӘШЕП ЯШӘРГӘ КИРӘК»

**Буа районының Бикмураз авылы мәчете имамы Илдус Әсәдуллин үзенең дин юлына кереп китүен: «Мине Ходай Тәгалә үзе чакырды, аның кодрәтеннән башка берниндә эш тә башкарылмый», – дип аңлата. Районда уңышлы эшләп килүче авыл имамнарының берсе ул.**

Буа машина төзү заводында 40 елдан күбрәк слесарь булып эшләгән Илдус абый, пенсиягә чыгарга берничә ел калгач, кыскартуга эләгә. Бу хәлне авыр кичерә ул. Гомерлек хезмәтеннән аерылып, өйдә утыруына бик эче поша. Тик соңрак бу үзгәрешнең Аллаһ кушуы буенча гамәлгә ашырылуын аңлый. Август ае ахырында эшеннән китәргә мәҗбүр булган Илдус Әсәдуллин көзге бакча эшләрен тәмамлагач, Буа мәдрәсәсендә уку өчен яңа төркем җыялар икән, дигән хәбәр ишетә. Буш вакыты күп булганлыктан, ике дә уйламыйча, кичке уку курсларына языла. Дини белем алу юлында 3 ел вакыт узганны сизми дә. 2016 елда ул дипломлы дин әһеле була.

Белеме булмаган, үзлегеннән өйрәнеп, моңарчы авыл мәчете имамы вазыйфаларын башкарган Вазыйх хәзрәт Нурмөхәммәтов Илдусның укып бетергәнен генә көткән сыман, озакка сузмыйча үз эшен аңа ышанып тапшыра.

– Алдан аптырап калдым. Гарәпчә яза, укый, сүрәләрне яхшы беләм анысы. Ә бит әле башка дини эшләр дә җитәрлек – яшьләргә никах уку, балага исем кушу, мәет юу, күмүне дә шартына туры китереп башкарырга кирәк. Дини китаплардагы күрсәтмәләр ярдәм итте. Аннан укый-укый өйрәндем. Шөкер, хәзер бер яктан да авырлык кичермим, – ди Илдус Әсәдуллин.

Мондый тәҗрибә белән калганы да килә. Болар – хуҗалык эшләрен алып бару, хәйриячелек кылу һәм башкалар.

Яңа имам күптән инде мәчеткә бару юлының начар булуына борчылган. Чокырланып беткән грунт юлдан автомобиль белән бару түгел, аягы начар йөргән өлкәннәргә җәяү килергә дә авыр була. Ул, мәхәллә картлары белән киңәшеп, шул нужалы 300 метрны ремонтларга – грунт җирне тигезләп, ком-таш катнашмасы салдырырга юлчы оешма эшчеләрен яллый. Авыл картлары моның өчен хәзер дә имамга рәхмәт әйтәләр.

Икенче эчпошыргыч нәрсә – яңа зиратның капкалары нык искергә. Монысын да озакка сузмый, яңа капкалар куйдыру өстенә, рәшәткаләрне дә яңабаштан буята. Бер зират эшләрен керешкәч, әкренләп икенчесенә дә чират җитә.

– Бу ташландык хәлдәге зират иде. Урын булмау сәбәпле, биредә 1928 елдан бирле бер кеше дә җирләнмәгән. Аксакаллар бу зиратта заманында дәрәҗәле кеше – Ахун хәзрәт күмелгәнлеген сөйлиләр, – ди Илдус хәзрәт бу хакта.

Әлеге зиратта да төзекләндерү эшләре башкарыла. Өстәвенә чистартыла да.

– Ике авыл зиратында да иске агачлардан чистарту эшләре тулысынча башкарылып бетмәгән әле. Менә язын техника яллап, зират кырыйларын басып киткән өрәңгеләрне кисеп, тамырларын алдырасы бар. Анналры инде бераз тынычланырга була, – ди Илдус хәзрәт.

Тыштагы эшләр генә түгел, мәчет эчендәгесе дә имам өстендә бит әле. Мәчетне җылыту системасын яңарткаппар. Ә бер ел элек яңа тәһарәтханә эшләп куйганнар. Су агызу җайланмалары да урнаштырылган. Чираттагы объект – мәчет янындагы ашханә. Әлегә ул җылытылмаган, җәйге вариант кына. Ремонт эшләре тулысынча тәмамланган, авыл халкы белән зурлап ифтар мәҗлесләре уздырырга исәп тоталар.

Гомумән, авылдашларын зурлау, авыр вакытта ярдәм итү канына сеңгән Илдус хәзрәтнең. Мәчет бусагасын атлап, күпләр хәсрәтен сөйли аңа. Йортлары янганнарны, катлаулы операция ясарга акча сорап килүчеләрне кире борып чыгарганы юк аның. Яшь гаиләләргә дә ярдәм иткән мәхәллә. Йортлары хуҗабикә вафат булгач, бурычларын түләргә дә булышканнар. Сәфәр кылучыларның да гозерен тыңлый ул.

– Хәдистә: мосафирның хәлен бел, гозере булса, үтә, диелгән. Тормышта бит төрле хәлләр була. Бер-беребезгә ярдәмләшеп яшәргә кирәк, – ди Бикмураз авылы мәчете имамы Илдус хәзрәт Әсәдуллин.

Әлфинур ЙОСЫПОВА

# ҖИДЕ КАТ ТИКШЕР, БЕР КАТ АЛ

**Кайбер авиакомпанияләр Россия буенча рейсларга караган билетларны алыштыру яисә кайтару өчен штраф бәясен арттырган. Бу хакта «РИА Новости» хәбәр итә. Юрист Роман Архипов, билет сатып алганда, авиакомпаниянең эчке кагыйдәләрен тәфсилләп өйрәнергә киңәш итә.**

Бу очракта штраф ул – өстәмә түләү түгел, ә билет бәясеннән авиакомпания тотып кала торган сумма. «Моны һәр компания үзе хәл итәргә хокуклы», – диде белгеч.

Белгеч белән без самолетка, поездга яисә күңел ачу чарасына билет алучыларның хокуклары турында сөйләштек, билеттән баш тартырга теләгән очракта нинди кагыйдәләрне үтәргә кирәклеген ачыкларга тырыштык.

**Авиабилет**

Россия Һава кодексының (Россия һава киңлекләреннән файдалану һәм авиация өлкәсендәге эшчәнлек мөнәсәбәтләрен җайга сала торган төп чыганак) 108 нче маддәсе нигезендә, теләсә кайсы пассажир билеттән баш тартырга хокуклы. Тик бу турыда ул авиакомпаниягә рейска кадәр кимендә 24 сәгать кала хәбәр итәргә тиеш (кайбер компанияләрдә моның өчен күбрәк вакыт бирелә).

Әлеге шарт үтәлсә һәм билетның кире кайтарып булмый торганы сатып алынмаган булса, пассажирга авиабилет өчен түләнгән акча кайтарылырга тиеш. «Ләкин билетны сатып алганчы, авиакомпаниянең «эчке» кагыйдәләрен бик игътибар белән өйрәнергә кирәк. Кагыйдә буларак, күп очракта авиабилет бәясен тулысынча кайтарып булмый. Шул ук вакытта компания билет бәясенең 25 процентыннан артык өлешен тотып кала алмый», – дип аңлатты юрист Роман Архипов.

Моннан тыш, очыш башка сәбәпләр аркасында булмый кала икән, пассажир билетның тулы бәясен кайтаруны таләп итә ала. «Ләкин беркемгә дә бәйле булмаган очракларда, әйтик, пандемия чорындагы кебек ситуацияләр белән очрашканда, хөкүмәт бу мәсьәләне мөстәкыйль рәвештә җайга сала, клиентлар һәм авиакомпанияләр арасында үзара хезмәттәшлекнең гомуми кагыйдәләрен билгели», – ди Роман әфәнде.

Авиабилет акчасын кайтару өчен, кая мөрәҗәгать итәргә соң? Пассажир тулы мәгълүматны үзе мөрәҗәгать иткән авиакомпаниянең рәсми сайтыннан, диспетчерлык хезмәтенә шалтыратып яисә үзе мөрәҗәгать иткән тур-агентлык аша белә ала.

**Поезд билеты**

Поездга алынган билет өчен акчаны (яки аның бер өлешен) кайтару таләпләре нидән гыйбарәт соң? FlyAllAround сайтындагы мәгълүматларга караганда, ул акчаны поезд кузгалып киткәнче (хәтта поездга соңга калган очракта да) кайтарып була. Әгәр дә сәфәрне гамәлдән чыгару өчен җитди сәбәп бар икән (авыру, кичектереп булмый торган проблемалар), бу кагыйдә билетның кайтарып булмый торган төренә карата эшләмәчәк.

pixabay.com

Билет акчасын кире кайтаруны мөмкин кадәр иртәрәк рәсмиләштерергә кирәк. Көтелмәгән хәлләргә тарымаган очракта, билгеле. Сәфәргә бара алмавыгызны алдан беләсез икән, шундук РЖДга мөрәҗәгать итегез. Шул очракта билет бәясенең күп өлешен кайтара алачаксыз.

Россия буенча сәфәр кылучы пассажирлар өчен түбәндәге кагыйдәләр актуаль санала:

– әгәр дә билетны 24 сәгать алдан (яки тагын да иртәрәк) тапшыра алсагыз, сатып алган вакытта ничә сум түләнгән, шуның кадәр акчаны кире кайтарырга була;

– билетны поезд кузгалырга сигез сәгать вакыт кала тапшырсагыз, сезгә билетның (плацкарт, хезмәт күрсәтү һ.б. белән бергә) тулы бәясен кайтарырга тиешләр (кайбер очракта комиссия акчасы тотып калына);

– әгәр дә сез билеттан поезд кузгаларга ким дигәндә ике сәгать кала баш тартсагыз, бары тик билет бәясе генә кайтарылачак;

– билетның ничә сәгать алдан кайтарылуына карамастан, пассажир 203 сум «штраф» түләргә тиеш, бу – Россия тимер юллары тарафыннан расланган рәсми сумма.

Билет акчасын кире кайтару өчен, якындагы тимер юл станциясендәге кассага мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ә электрон билеттән исә интернет аша да баш тартырга мөмкин.

**Кино/театр/концерт билетлары**

Бәйрәм чаралары (кино, театр, концерт) өчен билетларга килгәндә, монда бөтенләй башка кагыйдәләр расланган. Юрист Роман Архипов сүзләренчә, җитди сәбәпләр (авыру, гаилә әгъзасы яисә якын туганыңның үлеме) булган очракта, билеттән чара буласы көнне дә баш тартырга һәм билет бәясен тулысынча кайтарырга мөмкин.

– Моның өчен чара буласы датадан соңга калмыйча, гариза һәм тиешле документлар (авыруны раслаучы белешмә фотосы яки гаилә әгъзасы, якын туганының үлемен раслаучы таныклык фотосы) белән оештыручыга яисә билет сатып алган урынга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Билеттән башка сәбәпләр аркасында баш тартасыз икән, сез гаризаны өч көн алдан бирергә тиеш, – дип аңлатты ул.

Гаризалар исә каршы як тарафыннан якынча ун көн эчендә каралырга тиеш.

**Туризм буенча федераль агентлык даими рәвештә үзенең «Телеграм» каналында еш бирелә торган сорауларга җавап бирә. Рейс тоткарланган очракта пассажирларга нәрсә каралган соң?**

➤Рейс **ике** сәгатькә тоткарланса, ике тапкыр телефоннан шалтырату мөмкинлеге һәм салкын эчемлекләр;

➤тоткарлык **дүрт** сәгатьтән артса, туклану өчен талоннар;

➤тоткарлык көндезге якта – **алты**, төнлә **сигез** сәгатьтән артса, кунакханәдә номер, кунакханәгә кадәр трансфер һәм багаж саклау хезмәтеннән бушлай файдалану мөмкинлеге;

➤әгәр пассажирның җиде яшькә кадәрге баласы булса, авиакомпания аларны махсус бүлмә белән тәэмин итәргә тиеш. Бу очракта рейсның тоткарлану вакыты күпме булу мөһим түгел.

**1100 еллык тарих**



**Тарих фәннәре докторы, профессор Фаяз ХУҖИН ярдәме белән 1100 ел элек Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителү уңаеннан тарихи язмалар циклын дәвам иттерәбез. Болгар шәһәрләрендә озак еллар казу эшләре алып барган, ислам дине тарихын өйрәнүгә зур көч куйган галимгә шушы уңайдан сорауларыгызны да җиткерә аласыз.**

## *Исламның туган җире*

Исламның туган җире – VII гасырда борынгы ыруглык җәмгыятенең таркалуы һәм яңа феодаль тәртипләр барлыкка килү процессын кичергән Согуд Гарәбстаны. Төрле социаль катлаулар, сәяси партияләр һәм аларның идеологияләре арасында кискен конфликтлар белән үрелеп барган күчү чоры халыкны үзләре артыннан алга алып барырга сәләтле күренекле лидерларын тудыра. Гарәп җәмгыятенең иске, инде шактый какшаган нигезләре җимерелә башлаган бер чорда Абдаллаһ Абд Әл-Моталлиб улы Мөхәммәд (570–632) шундый лидер булып таныла.

Язмыш кушуы буенча вакыйгалар үзәгендә торып калган Мөхәммәд, мәҗүсилеккә бәйләнгән иске идеологиягә каршы көрәш башлап җибәрү өчен, нигезендә дөньяга бөтенләй башкача караш яткан яңа идеология булдырырга кирәклеген аңлый. Күңелендә әзерләнгән инстинктив рәвештә генә урнашкан бу фикер Мөхәммәдкә һич тынгы бирми. Яңа идеология, аның үйлавынча, Гарәбстан җирендә яшәп ятучы кусаншы, әш кына бер-берсе белән сугышып ятучы күчмә һәм ярым күчмә кабиләләрне берләштерү көченә ия булырга тиеш. Бердәнбер Аллаһы Тәгаләнең бөеклеген игълан итүче ислам тиздән әнә шундый идеологиягә әверелачак. Мөхәммәднең актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә Гарәбстанның барлык халкы диярлек исламга күчеп бетә.

Мөхәммәд исән вакытта уңышлы гына башланып киткән яңа дин тарату кампаниясе аның вафатыннан соң Гарәбстан ярымутравыннан читкә чыга. Йөз ел дәвамында, дөрес, бераз «тәнәфесләр» белән, көнбатышта Испания, Марокко һәм Мавританиядән башлап, көнчыгышта Пакьстан, Һиндстан һәм Бангладешка кадәр сузылган, төньякта исә Урта, Кара, Каспий һәм Арал диңгезләре, көньякта Африка Сахарасы һәм Һинд океаны диңгезләре белән чикләнгән зур территорияләр һәм шул җирләрдә яши торган халыклар Багдад хәлифәте хакимиятенә астына әләгә.

VII гасыр урталарында ук исламның Көнчыгыш Европага, хәзерге Россия җирләренә үтеп керүе башлана. Хәзерге Дагыстан территориясендә Хәлифәтнең төп көндәше – Хәзәр каһанлыгы. Гарәп-хәзәр сугышлары йөз елга якын дәвам итә. 737 елда полководец һәм булачак хәлиф Мәрван ибн-Мөхәммәдкә Хәзәр дәүләте белән солых килешүе төзергә туры килә. Шартнамә буенча Хәзәр каһаны, аның яраннары һәм кул астындагы халыклар, шул исәптән болгарларның да бер өлеше, җиңүчеләр динен кабул итәргә мәҗбүр ителә.

## Багдад илчелеге – Болгарда

Болгар илендә ислам дине таралу пәйгамбәребез Мөхәммәд заманында ук башлана дигән фикер риваять-легендаларга гына таяна һәм объектив чынбарлык белән расланмый. 630–660 нчы еллар тирәсендә, ягъни Кубрат хан идарә иткән чорда Бөек Болгар дәүләтенең халкы ислам дине тотмаган. Алардан соң калган зиратларда бары тик мәҗүси йолалар буенча күмелгән кеше сөякләре генә табыла. VII гасырның 60 нчы елларында Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң Урта Иделгә күчеп килүчеләрнең беренче дулкыны булып саналган болгарлар да үлгән кешеләрне мәҗүсиләр йоласы буенча күмгәннәр. Ләкин әле бу, болгар халкы ислам дине белән бөтенләй дә таныш булмаган, дигән сүз түгел. 922 елгы тарихи вакыйгалардан соң Болгардагы ислам тарихын Мөхәммәд пәйгамбәр белән бәйләргә омтылу барлыкка килә.

Болгарларның ислам динен кабул итү тарихында төп вакыйгаларның берсе, һичшиксез, бүген гади халык арасында Алмыш исеме белән танылган, чынлыкта исә 922 елга кадәр кимендә ике дистә ел элек үзенә Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ исеме алган Болгар ханы белән бәйле. Заманында аның титулы борынгы төрекиләрдәгечә эльтебер/илтабар/йылтывар (ил башлыгы, юлбашчы мәгънәсендә) дип йөртелгән, соңрак, ислам динен кабул иткәч, әмир дип атый башлаганнар.

921 елның язында Багдадка Абдаллаһ ибн-Башту җитәкчелегендәге илчелек килә. Ул ерак Болгардан Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ тарафыннан җибәрелгән була. Илче тарафыннан Габбасилар хәлифәсе әл-Мөктәдиргә тапшырылган хатында Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ аннан «дингә өйрәтүче, ислам диненең канунчарын аңлатучы, аның өчен мәчет төзеп бирүче, аның (хәлифәнең) исламн диненә өндәвен үзенең шәһәрендә һәм үзенең бөтен дәүләтендә халыкка җиткерү өчен аңа, Болгар патшасына, мөнбәр торгызучы кешеләр җибәрүен сораган һәм ул, Болгар патшасы, дошман патшалардан анда торып сакланасын өчен кәлгә (крепость) салуын үтенгән... Хат килгәч, аңа, Болгар патшасына, аннан, хәлифәдән, нәрсә сораган булса, шуны ризалык биреле».

921 елның 21 июнендә Багдадтан Болгар иленә Сусан әр-Расси һәм аның сәркатибе Әхмәд ибн Фадлан җитәкчелегендә зур кәрван-илчелек китә. Юл Хамадан, Рей, Нишапур, Мәрв һәм Бохара аша Хәрәземгә кадәр дәвам итә. Аннан соң кәрван зур кыенлык белән ярымчүле Үстюрт калкулыгы буйлап бара һәм Җаек (Урал) елгасына чыга. Ерак араларны үтеп, күчмә төрки халыклар биләп торган җирләр аша илчелек Иделгә якынлаша. Бу хакта Ибн Фадлан болай дип яза:

«Без болгарлар патшасыннан, ә ул – без бара торган кеше, бер көн һәм бер төн ара ераклыгында булганда, безне каршылау өчен үзенә буйсынган дүрт патшаны, ир туганнарын һәм улларын җибәргән иде. Алар безне каршыладылар, аларның ипиләре, итләре һәм тарылары бар иде, һәм алар безнең белән бергә кузгалып киттеләр. Һәм без болгарлар патшасыннан ике фәрсах ара ераклыгында булганда, ул безне үзе каршылады. Безне күргәч, атыннан төште, бөек һәм кодрәтле Аллаһыга табынып, рәхмәтләрен белдереп, йөзтүбән егылды. Аның җиң эчендә дирһәмнәр бар иде, һәм ул аларны безгә сипте. Ул безнең өчен чатырлар кордырды һәм безне аларга урнаштырды. Безнең аның янына килеп җитүебез – өч йөз уникенче ел мөхәррәм аеның уникенче төне үткәч, якшәмбе көнне булды» (хәзерге календарь буенча 922 елның 17 маена туры килә).

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Казанда яшәүче якын дустыбыз, озак еллар салым инспекциясендә эшләгән хезмәт ветераны Әлфинур Гомәр кызы ГЫЙЛЬМАНОВА бу көннәрдә үзенең олуг юбилеен бәйрәм итә!**

Кадерлебез Әлфинур Гомәровна! Сез – Саба районы Сауш авылында туып-үсеп, намуслы хезмәтегез, үз тырышлыгыгыз белән тормышта зур хөрмәт казанган кеше. Баштарак кино челтәрендә, аннары озак еллар салым инспекциясендә эшләгәндә, Сезнең хезмәтегез җитәкчелек тарафыннан төрле дәүләт бүләкләренә тәкъдим ителү дә юкка түгел. Яшьләргә – үрнәк остаз, хезмәттәшләрегезгә – тәҗрибәле киңәшче, һәркемгә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышасыз. Барчасы өчен дә зур рәхмәт. Игелекләрегез меңе белән үзегезгә кайтсын!

Матур юбилеегыз уңаеннан, Сезгә ныклы сәламәтлек, күңел тынычлыгы, киләчәк тормышыгызда берсеннән-берсе күңеллерәк, шатлыклырак яңалыклар теләп калабыз. Һәр аткан таң Сезгә бәхет алып килсен!

Иң изге теләкләр белән: Әминә һәм Әхәт Җиһангировлар, Дамир Әкрам улы Гыймадиев, Тухиннар, Никириналар гаиләсе.
Бу теләкләргә барлык туганнарыгыз, якыннарыгыз һәм дусларыгыз да кушыла.

**Спорт**

ak-bars.ru

# *Күңелсез булмаячак*

**«Ак барс»ның яңа тренеры булып Олег Знарок эшләячәк. Дүшәмбе көнне ул Татарстан башкаласына килде. Шушы көннәрдә Казан клубы аның белән килешү имзалар дип фаразлана. Өч тапкыр Гагарин Кубогын һәм Олимпиаданы откан остаздан нәрсә көтәргә?**

Билгеле булганча, узган атнада «Ак барс»та Дмитрий Квартальнов белән араны өзүләрен һәм 1 майга кадәр эшкә яңа тренер аласыларын игълан иттеләр. Апрель беткәнне көтәргә туры килмәде. Алдан ук әлеге вазыйфага кандидат булган ике остазның исемен башкаларныкына караганда күбрәк телгә алдылар. Казан клубы да соңгы көннәрдә социаль челтәрләр аша Зиннәтулла Билалетдинов белән Олег Знарокка ишарә ясап, хоккей җанатарларының күңел кылларын чиртте. Ә Татарстанның спорт министры Владимир Леонов «Ак барс»та инде барысының хәл ителгәнен һәм мөһим вазыйфага Знарокның киләсен әйткәч, сер капчыгы тәмам бушап калды. Бу атна башында исә тренер Казанга килде. Димәк, сөйләшүләр ахырына якынлаша һәм озакламый яклар кул кысышыр дип фаразларга җирлек бар.

Ни өчен нәкъ менә Олег Знарок? «Ак барс» Татарстандагы дистәдән артык профессиональ команда арасында аерым урын алып тора. Тамашачы игътибары мәсьәләсендә башкалар хоккейчылар белән берничек тә ярыша алмый. Бары аларның гына күкрәгенә республика гербы рәсеме ясалган. «Ак барс» спорт командасы гына түгел, Татарстан символларының берсенә әверелде. Шуңа күрә әлеге клубка игътибар һәм финанс ярдәмен кызганмаулары гаҗәп түгел. «Ак барс» елның-елында КХЛда төп фаворитларның берсе саналды. Әмма быел плэй-оффның беренче өлешендә үк абыну чынбарлыкның теләк һәм хыялларга бик үк туры килмәгәнен раслады.

Олег Знарокны чакыру команданы янә иң көчлеләр сафына кертү теләгенә бәйле. Заманында ул «Динамо» һәм СКА белән барлыгы өч мәртәбә Гагарин Кубогын отты. Мондый күрсәткеч белән ул һәм Зиннәтулла Билалетдинов кына горурлана ала. Россия җыелма командасы белән эшләгәндә, дөнья чемпионатында уңышка иреште, планетаның иң көчле уенчылары чыгыш ясамаган Олимпиадада 26 ел көтелгән җиңүне яулады. Кыскасы, осталыгы шик уятмый. Әмма моның өчен кул астында көчле уенчылар булу кирәк. Знарокның соңгы эш урыны «Спартак»та иде. Анда исә ул уртакул команда белән әллә ни майтара алмады.

Бу остазның барлык белгечләр дә таныган бер сыйфаты бар: ул көчле уенчылар белән уртак тел табып, аларны зур көрәшкә алып чыга белә. Дөньякүләм танылган хоккейчылар аның артыннан иярергә әзер. Шул ук вакытта Знарок көндәшләрне чыгырыннан чыгару алымнарын да яхшы белә. Хисле кеше икәне дә күпләргә мәгълүм: телен дә яшерми, кулы да тик тормый. Кыскасы, бу остаз белән командага да, җанатарларга да күңелсез булмаячак.

Яңа тренер белән килешү имзалангач, Казан командасында зур үзгәрешләр башланачак. Аңлашыла инде, яңа тренер үзенә туры килгән состав туплаячак. Элеккесе яхшы булса, Знарокны чакырып та тормаслар иде. «Ак барс»ка килү ихтималы булган дистәләгән танылган хоккейчы телгә алына. Әмма үзгәрешләр яңа тренерлар һәм уенчылар килү белән генә чикләнмәскә мөмкин. Кайбер матбугат чаралары зур үҗәтлек белән башкала клубына җитәкче вазыйфасына Зиннәтулла Билалетдиновның билгеләнәсен хәбәр итә. Әлегә кадәр КХЛ тарихында бу дәрәҗәдә тәҗрибәле ике белгечнең бер клубта эшләгәне юк иде.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

# МӘРХӘМӘТЛЕ ТАМАША

## ВАҺАПОВ ФОНДЫ, ДОНБАССКА ГУМАНИТАР ЯРДӘМ ЙӨЗЕННӘН, ХӘЙРИЯ КОНЦЕРТЫ УЗДЫРДЫ

**«Ул китә инде Донбасска, сүз бирдек ташлашмаска...» Марсель Вәгыйзов шушы көйне сузуга, бөтен зал тынып калды. Татарның канына сеңгән көйләрнең берсе шул ул. Ваһапов фондының Донбасс халкына гуманитар ярдәм йөзеннән уздырган хәйрия концертының да нәкъ шул җырдан башлануы очраклы түгел.**

vk.com

Донбасс – татар халкы өчен чит җир түгел. Бу турыда концерт дәвамында да кат-кат әйттеләр. Татарлар арасында XIX йөз ахырында ук андагы шахталарга эш эзләп китүчеләр аз булмаган. Татар җырын, татар моңын да яраткан Донбасс халкы. Рәшит Ваһаповның ул якларда куйган концертларыннан алып кайткан хатлары әнә шул турыда сөйли. Мәшһүр җырчыга карата ихтирам, соклану хисләре кушып язылган хатларны сәхнәдән дә яңгыраттылар.

Ләкин әлеге концертның төп максаты хатирәләр яңарту, тарих битләрен актару гына түгел, ә Донецк һәм Луганск халкына мөмкин булганча ярдәм күрсәтү иде. Бу идеяне хуплаучыларның күп булуы бик сөендерә, ди Ваһапов фонды җитәкчесе Рифат Фәттахов.

– Әлеге чараны оештырырга безне берәү дә мәҗбүр итмәде. Бу концерт – җан авазы, йөрәк кушуы. Безнең тәкъдимне беренче көннән үк хуплап, күтәреп алучыларның күп булуы бик сөендерә, әлбәттә. Бүгенге концертта катнашучы татар артистларына да зур рәхмәт. Без аларны сүгәргә, тәнкыйтьләргә гадәтләнгән инде. Ләкин бу концертка әзерләнгән вакытта, минем аларга карата ихтирамым, горурлык хисем артты. Бүгенге авыр шартларда кайбер Россия йолдызларының чит илләргә качкан мәлендә, безнең татар артистлары Донбасска гуманитар ярдәм күрсәтү идеясе тирәсендә тупланды. Һәм бу бик табигый дә, чөнки татар халкында электән патриотизм, туган илгә мәхәббәт хисе бик көчле булган һәм булачак та.

Рифат Фәттахов килгән тамашачыга да рәхмәтен җиткерде. Бу концертта барлыгы 619 мең сумнан артык акча җыелган. «Бу акчаны соңгы тиененә кадәр «Ак Барс – Созидание» ярдәм фондына күчердек», – диде Рифат әфәнде. Аның сүзләренчә, бу сумманың яртысы Донецк шәһәрендә урнашкан татар мөселман җәмгыятенә тапшырылачак.

### «Бу очрашу – бердәмлекнең бер билгесе»

Мәрхәмәт – инде күптән татар халкының канына сеңгән һәм буыннан-буынга күчеп килә торган хис. Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев шулай ди.

– Соңгы елларда Донецк һәм Луганск халык республикалары халкы гаять авыр шартларда яши. Аларның күбесе бүген мәҗбүри рәвештә эвакуацияләнде. Россия, аерым алганда, Татарстан исә әлеге республикалардан килгән кешеләрне сыендырып, аларга ярдәм итәргә әзер булуын күрсәтте. Республиканың бик күп зур оешмалары гуманитар ярдәм җыйды. Шул рәвешле без кабат үзебезнең бердәм булуыбызны, башкаларга кайгы килгәндә читтә кала алмавыбызны расладык. Бу очрашу да – шушы бердәмлекнең бер билгесе, – дип сөйләде ул кичәдә.

Хәйрия концертының үзенчәлекле кунаклары – «Донбасс» дәүләт җыр һәм бию ансамбле. Коллективның концерт эшчәнлеге буенча генераль директор урынбасары Николай Захаров сүзләренчә, Татарстан тамашачысы – алар өчен күптәнге дуслары кебек. «Без татар тамашачысын бик яратабыз, инде менә өченче тапкыр очрашуыбыз. Быел безнең ансамбльнең матур юбилее, аны да бергә-бергә уздырырбыз дип өметләнәм», – диде ул.

Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова ерак араны якын итеп килгән кунакларга рәхмәтен җиткерде. «Мәрхәмәтлелек – безнең өчен буш сүз түгел. Бүгенге күркәм чарага үз өлеше кергән һәркемгә хөрмәт һәм рәхмәт сүзләрен әйтәсем килә», – диде ул.

Концерт кунаклары арасында Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева да бар иде. «Донецк һәм Луганск халык республикаларына ярдәм фонды нәкъ менә сезнең үтенеч белән ачылды. Беренче көннән үк Иҗтимагый палата Татарстан халкыннан «Мин ничек ярдәм итә алам?» кебек мөрәҗәгатьләр кабул итә башлады. Фонд ачылгач, кемдер пенсиясеннән өлеш чыгарды, кемдер хезмәт хакын җибәрде. 18 апрельдә бу фондка үз өлешен Президентыбыз да кертте. Без – «Шахта» көен тыңлап үскән буын. Аның һәр сүзе халык хәтерендә уелып калган. Донбасс халкы безгә чит түгел. Алар авырлык кичергәндә, без берничек тә тыныч йөри алмыйбыз», – диде ул.

Концертта катнашучы татар җырчылары арасында исә Зәйнәб Фәрхетдинова, Зөфәр Билалов, Илһам Вәлиев, Зөһрә Шәрифуллина, Нәфкать Нигъмәтуллин, Газинур Фарукшин, Азат Тимершәех, Ил-Саф, Раяз Фасыйхов, Алинә Шәрипҗанова, Артур Исламов һәм башкалар бар иде.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

# «МИНЕМ ХАТЫН КЕБЕК БУЛА АЛМАССЫЗ»

**Апас районының Дәвеш авылына баргач, Гүзәлия Латыйпованы авылдашлары бик мактап телгә алды. «Кулыннан килмәгән эше юк аның. Бәйли дә, чигә дә, матур итеп җырлый да. Авыруы булса да, зарлануны белмәс, йөзеннән елмаюы китмәс», – диделәр аның турында. Аның белән танышкач, тормышка, кешеләргә булган мөнәсәбәте безне дә сокландырды.**

– Мин – икенче группа инвалид. Сабый чагымда караваттан егылып төшкәнмен. Зәгыйфьлегемне шуннан күрәләр, – диде ул, язмышын бәян итеп. – Әни хастаханәгә барган үзе, тик ул вакытта авыл кешесенең табибтан табибка йөрерлек мөмкинлеге булмаган. Аннан соң табиблар да миндәге авыруларны салкын тиюдән күргәннәр. Әнинең сөйләве буенча, мине кулга алып күтәргән саен, авыртуны белдереп, ыңгырашып куя торган булганмын, – дип искә ала Гүзәлия ханым.

Авыру үзен ачыктан-ачык берничә ел сиздерми әле. Җитди үзгәрешләр исә кыз дүртенче сыйныфта укыганда башлана: аның умыртка баганасы зәгыйфьләнә.

– Ләкин аңа карап, төшенкелеккә бирелә торган кеше түгелмен. Дөньяның ямен табып яшәргә тырышам. Гомерем буена хыялларыма таба атлыйм, – ди ул.

Ә хыяллары зурдан була тырыш кызның. Тик, кызганыч, кайгылары да бер-бер артлы ишелеп төшә.

– Башта авырып, 31 яшьлек абыем, алты көннән соң 54 яшьлек әнием үлде. Баласының үлемен күтәрә алмады. Аңа кадәр ул ун баласының өчесен җир куенына салган иде инде. Бер апам 2,5 яшьлек чагында күз тиеп харап булган. 10 яшьлек сеңлемнең гомере минем күз алдымда өзелде: суга батты. Тагын бер туганыбыз үле килеш туды, – дип, авыр хатирәләрен барлады.

Әниләре вафат булгач, Гүзәлия апа, Кайбычтагы эшен калдырып, энеләрен карарга кайта. Күпмедер вакыттан соң бер туганын армиягә озата.

– Аңа: «Наным, кеше төсле яшәргә теләсәң, армиядә кал», – дип киңәш иттем. Сүземне тыңлады – хәрби булды. Икенче энем шушы авылда тора. Өч абыем бар. Туганнарым белән бик дус яшибез, – диде Гүзәлия апа.

Шушы авырлыклар Гүзәлия апаны булачак ире Илвир белән тагын да якынайта. Дөрес, аңа кадәр дә, абыйсының сыйныфташы буларак, аралашып йөргән булалар. Ләкин егет кызга карата булган җитди уйларын шушы хәсрәтләрдән соң гына белдерә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Илвир яныма килеп: «Тугыз ел күзәтеп йөрим, килергә кыюлыгым җитмәде», – диде. Дөресен генә әйткәндә, әтиебез хәмер белән күп мавыкты. Әнинең үзенең үзәгенә үткәнгәдер инде, мине: «Кызым, андый кешеләргә борылып та карама», – дип үстерде. Шуңа күрә бераз гына эчкән кешедән дә уттан курыккан кебек курка, якын китерми идем. Тик авылдашыбыз, якын кешем Роза апаның сүзләрен колагыма керттем. «Ир туганнарыңа гомер буе хезмәтче булып яшәмәссең бит инде. Ник куасың аны? Начар кешегә охшамаган бит», – диде ул. Шуннан соң гына якынрак аралаша башладык. Баштарак иремә: «Шушы чибәрлегең белән сәламәт хатын таба алмадыңмыни?» – дип әйтүчеләр дә булды. Ә ул һәрвакыт: «Сез 5–6 тапкыр яңадан тусагыз да, минем хатын кебек була алмассыз», – дип әйтә килде.

Бүгенгесенә шөкер итеп туя алмый Гүзәлия апа. Гомер буе иренең кайгыртуын тоеп яшәгән. Тормыш корып җибәргәч, авылдагы бер кечкенә генә йортны сатып алалар. Гаиләләрен тагын да түгәрәкләп, уллары Илсаф туа. 2200 граммлы булып туган бала бүген инде сигезенче сыйныфта укый. Ике елдан соң кызлары Алия гаиләгә тагын да ямь өсти. Ул арада йортларын да үзләре теләгәнчә зурайтып, матурлап бетерәләр.

Авылдашлары дөрес әйтә: Гүзәлия апа – бик тырыш, уңган хатын. Йорт эшләреннән бушаган арада башмак, җиңсез кофта, оекбаш, урындык япмалары, бәби киемнәре һәм башка бик күп нәрсәләр бәйли, тегә.

– Әнием бик оста бәйләүче, чигүче иде. Үзем дә гомер буе кул эшеннән аерылмадым. Тегү, бәйләү эше миңа җан рәхәте бирә. Аларны сирәк сатам, чөнки күпчелеге күчтәнәчкә, бүләккә китеп бара. Туганнарым, дусларым күп. Бәйләгән бер әйбер китә тора. Кызыма сәхнә күлмәкләренә кадәр тегеп кидердем. Чәчәкләр, бакча эшен дә бик яратам. Бик игътибарлы, тиз истә калдыручан мин. Бер карау җитә. Кеше тикшерергә, гайбәт сатарга бер минут та вакытым юк. Файдалы эш эшләмәсәм, күнем бушка узган кебек. Мин тормыш мәгънәсен шуннан табам, – ди ул.

Җырлау дигәннән, Гүзәлия апа үзе дә бик моңлы җырлый икән. Районда уза торган бәйгеләрдә дә еш катнаша.

– Мин тормыштагы уңай якларга күбрәк игътибар бирергә тырышам. Начарлык турында гына уйласаң, сөйләсәң, ул артканнан-арта гына бара, – дигән фикердә ул. – Хәзер күп нәрсәләргә җиңелрәк карарга өйрәндем. Роза апаның да киңәшләрен истә тотып, гаиләдәге аңлашылмаучылыкларны уртага салып сөйләшергә, бер-беребезгә юл куярга өйрәндек. Ирем – минем киңәшчем дә, сердәшем дә, дустым да. Гаиләнең тынычлыгы күп очракта хатын-кыздан тора.

Зөһрә САДЫЙКОВА

**Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 256

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

**www.vatantat.ru**

**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**

**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР

**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+